ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.05.2017 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1313**

Зеленодольск муниципаль районында җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта);

1.2. җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта);

1.3. муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта);

1.4. җир кишәрлеген түләүсез сроксыз файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта);

1.5. муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта);

1.6. муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

2. «Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 10 апрелендәге 744 номерлы карарының 21, 29-32 номерлы кушымталары үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск

муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

Зеленодольск муниципаль районның
Башкарма комитет Җитәкчесе А.Х.Сәхибуллин

1 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 23 маендагы
1313 номерлыкарарына

.

**Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүбуенча административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү, хезмәт күрсәтү) билгели.

Әлеге Регламентның гамәлдә булуы Зеленодольск муниципаль районы территориясендәге муниципаль милектәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә кагыла.

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүче).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы - «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (алга таба - Палата).

Документларны кабул итү «Зеленодольск муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» муниципаль бюджет учреждениесендә (алга таба - КФҮ) башкарыла.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты.

Эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр билгеләнә.

Палатаның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 38 нче йорт

Эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

кабул итү көне: сишәмбе: 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр билгеләнә.

Палатаның белешмә телефоны: 4-21-07 (кабул итү бүлмәсе).

Керү шәхесне таныклый торган документлар буенча

Керү ирекле, алдан язылу таләп ителми.

КФҮ урнашкан урын: Зеленодольск шәһәре, Беренче Май ур., 14 нче йорт

Эш графигы:

дүшәмбе, чәршәмбе, шимбә, якшәмбе 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

сишәмбе, пәнҗешәмбе көнне 10.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр (2016 елның 07 сентябреннән сишәмбе көннәрендә 10:00 дән 20:00 гә кадәр);

җомга 7.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә (алга таба- «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындаЗеленодольск муниципаль районы сайтының (алга таба – Зеленодольск муниципаль районы сайты) адресы:http://zelenodolsk.tatarstan.ruПалатаның электрон адресы: Palataizo@yandex.ru к

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүматны түбәндәге ысуллар белән алырга мөмкин:

1) Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Палата биналарында урнашкан муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт күрсәтү турында белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша Зеленодольск муниципаль сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) ;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https:/ www.gosuslugi.ru);

5) Палатада:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон буенча;

язмача (шул исәптән ЭЦП таныклаган электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә - кәгазь саклагычта почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.4. Палата белгече мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматны Зеленодольск муниципаль районы сайтында һәм Палата биналарында мәгълүмат стендларында урнаштыруны тәэмин итә.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Граждан кодексының 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба - РФ ГК) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);

Россия Федерациясенең 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы җир кодексы (алга таба - РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 29.10.2001, №44, 4147ст.);

«Җир төзелеше турында» 2001 елның 18 июнендәге 78-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 78-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 25.06.2001, № 26, 2582 ст.);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 06.10.2003, №40, 3822 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 27 ноябрендәге«Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын әзерләү таләпләрен раслау турында, территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын электрон документ рәвешендә әзерләгәндә территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы, әзерләү кәгазь чыганакта документ рәвешендә башкарыла торган территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы рәвешләрен раслау турында» 762 номерлы боерыгы белән Россия Федерациясе (алга таба-762 номерлы боерык)(Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru 18.02.2015);

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 45-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004);

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав) («Зеленодольская правда», №№253-256, 31.12.2005 ел);

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 1 февралендәге 39 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе турында нигезләмә (алга таба – Палата турында нигезләмә) («Зеленодольская правда», № 40, 01.03.2006);

«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесенең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән.

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, мөрәҗәгать итүчеләргә консультацияләр бирү тәрәзәсе;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән белешмәләрнең (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең) алар нигезендә белешмәләр кертелә торган документлардагы белешмәләргә тәңгәл килмәвенә китергән хата (басма язу хатасы, ялгыш, грамматик яки арифметик хата яки шуңа охшаш хата);

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза астында (алга таба - гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 п.). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 нче кушымта).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка куелган таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күсәтүнең атамасы | Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү | 39.15 ст., 39.18 ст. |
| 2.2. Җирле үзидарәнең турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтә торган башкару-оештыру органы исеме | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет),<br>«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (алга таба - Палата) | РФ Җир кодексының 3.2 статьясы,<br>ТР ЗК 5 статьясы,<br>Палата турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | 1. Җир кишәрлеген алдан килештерү турында карар.<br>2. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында хат.<br>3. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар (хат) | РФ ЗК 39.15 ст. |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген дә исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Гариза кергән көннән алып утыз көн эчендә | РФ Җир кодексының 39.15 ст.7 п.<br>РФ ЗК 39.18 ст.1 п.1 пп. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең төгәл исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | 1) Гариза;<br>2) Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген аукционнар үткәрмичә сатып алу хокукын раслаучы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән исемлектә каралган документлар, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә вәкаләтле органга тапшырылырга тиешле документлардан тыш;<br>3)Җир кишәрлегенең урнашу схемасы, әгәр соралган җир кишәрлеген булдырырга кирәк булса һәм чикләрендә шундый җир кишәрлеге булдырырга тиешле территорияне ызанлау проекты булмаса;<br>4) урман кишәрлеген алдан килештерү турында гариза бирелгән очракта, урман кишәрлекләренең урнашу урыннары, чикләре, мәйданнары һәм башка санлы һәм сыйфатлы характеристикалары турында проект документлары;<br>5) мөрәҗәгать итүче вәкиленең, җир кишәрлеген алдан килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>6) мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очракта, юридик затны дәүләт теркәве турында документларның чит ил законнары нигезендә таныкланган тәрҗемәсе;<br>7) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма тарафыннан әзерләнгән, аның әгъзалары исемлекләре, әгәр җир кишәрлеген алдан килештерү турында яисә яшелчәчелек яисә бакчачылык алып бару өчен әлеге оешманы түләүсез | РФ ЗК 39.15 ст.2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | файдалануга бирү турында гариза бирелгән булса.<br>Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Зеленодольск муниципаль районы сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда түбәндәге ысулларның берсе тарафыннан бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>заказлы почта юлламасы белән тапшыру турында хәбәрнамә белән.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен норматив | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге документлар алына:<br>1) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык белешмәләр булган) (бинага, төзелешкә, корылмага хокуклар турында);<br>2) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; дәүләт органы, җирле үзидарә органы йә шушы документлар белән эш итүче оешма | реестрыннан (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык белешмәләр булган) өземтә (җир кишәрлегенә хокуклар турында);<br>3) Күчемсез мөлкәт объектының кадрлар паспорты;<br>4) ЕГРЮЛдан яисә ЕГРИПтан белешмәләр.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә торган һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган гамәлгә ашыра торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | «Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» муниципаль бюджет учреждениесе;<br>Башкарма комитет җитәкчесе | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.8. Муниципаль хезмәт | 1) документларның тиешле булмаган зат | Әлеге Регламент белән |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | тарафыннан тапшырылуы;<br>2) тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага теркәлгән документларда алдан әйтелмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлап була алмый торган җитди бозылулар булу;<br>4) Документлар тиешле булмаган органга тапшыру | билгеләнә |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр:<br>Гаризаны карау вәкаләтле органга әлеге гаризага кушылган җир кишәрлеге урнашу схемасында каралган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза килгән көнгә мондый орган каравында элек башка зат тарафыннан тәкъдим ителгән җир кишәрлеге урнашу схемасы һәм әлеге схемаларда каралган җир кишәрлекләренең өлешчә яки тулысынча урнашкан булса, гаризаны карау туктатып торыла.<br>Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гаризаны алдан карау срогы җир кишәрлеген урнаштыруның элек бирелгән схемасын раслау хакында карар кабул ителгәнчегә кадәр яисә әлеге схеманы раслаудан баш тарту турында карар кабул ителгәнчегә кадәр туктатылып тора.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турындагы гаризага теркәп бирелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 статьясының 16 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча раслана алмый; | РФ Җир кодексының 39.15 ст.6 п.<br><br>РФ Җир кодексының 39.15 ст.8 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | 2) булдырылырга тиешле җир кишәрлеге мөрәҗәгать итүчегә РФ Җир кодексының 39.16 статьясындагы 1 - 13, 15 - 19, 22 һәм 23 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләрдә бирелә алмый;<br>3) чикләре «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиешле җир кишәрлеге мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.16 статьясындагы 1 - 23 бүлекләрендә күрсәтелгән нигезләрдә бирелә алмый. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта | Муниципаль хезмәттән файдалану турында гариза бирү вакыты, чират булган очракта, 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан | Әлеге Регламент белән билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| көтүнең максималь срогы | артмаска тиеш | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризасын теркәү, шул исәптән электрон формада теркәү срогы | Гариза килгәннән соң өч көн эчендә | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларның күрсәтелгән объектлардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә, әлеге хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Кәгазьдә гариза Башкарма комитетка, КФҮкә, эш графигына туры китереп читтән торып эш урынына бирелә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла:<br>һава кондиционерлау системасы;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документларны рәсмиләштерү өчен җиһазлар;<br>мәгълүмат стендлары белән;<br>инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү мөмкинлеген булдыра торган чаралар һәм җиһазлар белән. | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең уңайлылык һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Палата бинасы җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашкан;;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең | Әлеге Регламент белән билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләре саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыннарында муниципаль хезмәт күрсәтү алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр аша | җитәрлек санда булуы;<br>инвалидларга башка кешеләр белән беррәттән муниципаль хезмәт алуга комачаулаучы каршылыкларны җиңәргә ярдәм күрсәтү;<br>сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;<br>алып йөртүче этне Палата бинасына кертүгә рөхсәт;<br>Мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән билгеләнә:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларга документларны тапшырганда чират булмавы ;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр булмау .<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазифаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла. Аралашу дәвамлылыгы | |

| | | |
|---|---|---|
| | регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба - КФҮ) , КФҮ читтән торып эш урыннарында күрсәтелгәндә консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм тапшыруны КФҮ белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан https://www.gosuslugi.ru сайтында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, КФҮ сайтында алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү законда каралган очракта, гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) яисә Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (https:/ www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

**3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү срогы, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре**

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә эзлекле гамәлләр тасвирламасы

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:
1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;
2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;
3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр булдыру һәм җибәрү;
4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;
5) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.
3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 2 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр күрсәтү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче Палатага шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма гариза тапшыра һәм документларны шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә тапшыра. Документлар читтән торып эш урыны аша бирелергә мөмкин. Читтән торып эш урыннары исемлеге 3 нче кушымтада китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Интернет кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада кабул ителгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2. КФҮ белгече яки Башкарма комитет белгече гаризаларны кабул итә, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышанычнамә белән эш иткән очракта);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә (документларның күчермәләрен тиешенчә ясау, документларда төзәтүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка килештерелмәгән төзәтүләрнең булмавын).

Кисәтүләр булмаган очракта, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм аны махсус журналда терки;

мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне башкару датасы һәм вакыты турында билге куелган документлар исемлегенең күчермәсен тапшыра;

Гаризаны Палата җитәкчесенә карауга җибәрү.

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, КФҮ белгече йә Башкарма комитет белгече, документларны кабул итүне алып баручы, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар барлыгы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язма аңлатма белән документларны кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

гаризаны һәм документларны 15 минут эчендә кабул итү;

гаризаны теркәү, гариза килгәннән соң өч көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Палата җитәкчесе каравынаҗибәрелгән яисә мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Палата җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга юллау.

3.4.1. Палата белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә шушы Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турындагы рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә, соратып алына торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса, документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Палатага җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне әзерләү һәм аның нәтиҗәсен бирү

3.5.1. Палата белгече килгән документлар (белешмәләр) нигезендә әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерә.

3.5.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу яисә туктатып тору өчен нигезләр булган очракта, Палата белгече муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында,муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, хат проектын яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында хат проектын әзерләүне гамәлгә ашыра һәм Палата җитәкчесенә җибәрә.

Палата җитәкчесе хатны карый һәм имзалый, хат теркәү өчен Башкарма комитетның гомуми бүлегенә җибәрелә.

Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгече хатны терки һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган һәм теркәлгән хат яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында хат.

3.5.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу яисә туктатып тору өчен нигезләр булмаган очракта, Палата белгече:

- җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында хәбәр итүне бастырып чыгаруны тәэмин итә - алга таба Хәбәр итү кәгазе (Хәбәр итү кәгазе буенча

гаризалар килүне көтү вакыты 30 календарь көн), (Хәбәр итү кәгазе буенча гаризалар килүнең көтү вакыты муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми);

- Җир кишәрлеген алдан килештерү турында Башкарма комитет карары проектын әзерли (башка гражданнардан, крестьян-фермер хуҗалыкларыннан гаризалар килмәгән очракта) (алга таба - Карар проекты) яисә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында хат (башка гражданнардан, крестьян-фермер хуҗалыкларыннан гаризалар килгән очракта);

- Карар проектын Палата җитәкчесенә (ул вәкаләт биргән затка) килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы җиде көн дәвамында гамәлгә ашырыла;

- Карар проектын «ЗМР юридик бюросы» МБУ килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы өч көн дәвамында гамәлгә ашырыла;

- Карар проектын Башкарма комитет җитәкчесенә имзага җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палата җитәкчесе һәм «ЗМР юридик бюросы» МБУ белән килештерелгән, Башкарма комитет җитәкчесенә (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) имза салуга юнәлтелгән Карар проекты.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура соралган документлар (белешмәләр) алынганнан соң ун көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Башкарма комитет җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат) карарны имзалый һәм аны Башкарма комитет мөһере белән таныклый. Имзаланган карар Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгеченә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура Карар проекты раслауга кергән көннән соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган Карар.

3.5.3. Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгече:

Карарны терки;

Палатага җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура теркәлүгә Карар проекты кабул ителгән көннән алып бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән Карар.

3.5.4. Палата белгече:

Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерә, рәсмиләштерелгән Карар яисә кире кагу турында хат яисә туктатып тору турында хат бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар теркәлгән баш тарту турында хат яки туктату турында хат яки карар кабул ителгән көннән алып бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.5.5. Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән карарны кул куйдырып яки баш тарту турында хат яки туктатып тору турында хат бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

- муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында Карар яки хат яки туктату турында хат бирү - мөрәҗәгать итүче килгән көнне, чират тәртибендә 15 минут эчендә;

мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) хатны алу өчен махсус рәвештә Палатага килү мөмкин түгеллеге турында хәбәр иткән очракта, хаттан баш тарту турында хатны яки туктату турында хатны почта аша хат белән җибәрү - әлеге Регламентның 3.5.4 пунктчасында каралган процедура тәмамланган мизгелдән бер көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында бирелгән карар яисә хат яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында хат.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Палата белгече:

карарларны теркәү журналында Башкарма комитет җитәкчесе кул куйган Карарны терки;

мөрәҗәгать итүчегә Карарны кул куйдырып бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән Карар.

3.7. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.7.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.7.2. Муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәк аша күрсәтү күпфункцияле үзәкнең билгеләнгән тәртиптә расланган хезмәт регламенты нигезендә башкарыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәт алуга КФҮдән документлар килгәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3 - 3.6 пунктлары нигезендә башкарыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документта техник хаталар ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Палатага түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (4 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган техник хаталы документны;

техник хаталар булуны дәлилли торган, юридик көчкә ия документларны.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырыла.

3.8.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү

турында гариза кабул итә, гариза белән кушымта итеп бирелгән документларны терки һәм аларны Палатага тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Палата белгеченә карауга юнәлтелгән гариза.

3.8.3. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатларында административ Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, һәм мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен кире алып, имза куйдырып, мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) төзәтмәләр кертелгән документны тапшыра яисә мөрәҗәгать итүче адресына, мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган документның төп нөсхәсен Палатага тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта кулланып) хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыклангannнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## Муниципаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларга виза салу тора;

2) эш алып баруны билгеләнгән тәртиптә тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр

(комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатендәге мәсьәләләр карап тикшерелергә мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр кылуга контроль һәм карарлар кабул итү максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы Палата рәисе, шулай ук Палата белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазифаи затлар исемлеге җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрдәнләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланса, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре вакытында карап тикшерелмәве өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм кылынган гамәлләр (гамәл кылмау) өчен закон белән билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору муниципаль хезмәт күрсәткәндә Палата эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять итүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар Палатаның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре Палаткага, Башкарма комитетына яисә Муниципаль берәмлек советына судка кадәр тәртиптә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәттән файдалану турында мөрәҗәгатен теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Зеленодольск муниципаль районының башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять язма формада кәгазь чыганакта яки электрон формада бирелә.

Шикаятьне почта аша, КФҮ аша, "Интернет" челтәреннән файдаланып, http://uslugi.tatar.ru рәсми сайты, Зеленодольск муниципаль районы сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/), шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән алып унбиш көн эчендә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта - аны теркәгән көннән алып биш көн эчендә..

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтә торган органның, хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәренең исем-атамасы;

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр - физик зат яки исеме, мөрәҗәгать итүче - юридик зат урнашкан урын, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап бирелергә тиешле почта адресы турында белешмәләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда язылган хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа беркетелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять, аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы зат тарафыннан, имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Палата җитәкчесе (Башкарма комитет җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кабул ителгән карарныгамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән түләтү каралмаган акчаларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару формасында, шулай ук башка формаларда да шикаятьне канәгатьләндерә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап юллана.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазифаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

1 нче кушымта

_____________________________________________
(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)

_____________________________________________
(физик затлар өчен-фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)

_____________________________________________
(юридик затлар өчен-атамасы, урнашу урыны, оештыру-хокукый рәвеше, ЕГРЮЛ, ОГРН дәүләт теркәве турында белешмәләр)

_____________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Җир кишәрлеген алдан килештерү турында
гариза

Сездән ______________________________________________нигезендә
(РФ ЗК.39.3 ст.2 п.3, 39.5 ст., 39.6 ст.2 п.2 п., 39.10 ст.2 дә каралганнардан нигез күрсәтелә).

______________________________________________________________

______________________________________________________________
(җир кишәрлегеннән файдалану максаты күрсәтелә)

өчен җир кишәрлеген бирүне алдан килештерергә
җир кишәрлеге ____________ кв.м., кадастр номеры ________:_____, ____________________рөхсәт ителгән файдалану төре белән, ________________________________________ : _____________ муниципаль район (шәһәр округы), торак пункт__________________________ йорты. _________________, ______________________________________________________________ ___адресы буенча урнашкан җирләр категориясеннән.
(мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген сатып алырга тели торган хокук төре)

Өстәмә белешмәләр (түбәндәге шартлар булганда тутырыла):

______________________________________________________________
җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеге урынына бирелгән очракта, дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеген алу турында карар реквизитлары;

______________________________________________________________
әгәр җир кишәрлеге әлеге документта һәм (яисә) әлеге проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелгән булса, территориаль планлаштыру документын һәм (яисә) территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар реквизитлары;

Гаризага түбәндәге документлар (сканерланган күчермәләр) теркәлә:

1) мөрәҗәгать итүченең сәүдә үткәрмичә җир кишәрлеген алу хокукын раслый торган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән исемлектә каралган документлар, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә вәкаләтле органга тапшырылырга тиешле документлардан тыш;

2) җир кишәрлегенең урнашу схемасы (әгәр соралган җир кишәрлеген

булдырырга кирәк булса һәм аның чикләрендә шундый җир кишәрлеге булдырырга тиешле территорияне чикләү проекты булмаса);

3) урман кишәрлекләренең урнашу урыннары, чикләре, мәйданнары һәм башка сан һәм сыйфат характеристикалары турында проект документациясе (әгәр урман кишәрлеген алдан килештерү турында гариза бирелгән булса);

4) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр җир кишәрлеген алдан килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать итсә);

5) чит дәүләт законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәве турында документларның рус теленә таныкланган тәрҗемәсе (әгәр мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булса);

6)гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма әгъзалары исемлекләре (әгәр җир кишәрлеген алдан килештерү турында яисә яшелчәчелек яисә бакчачылык алып бару өчен әлеге оешманы түләүсез файдалануга бирү турында гариза бирелгән булса).

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, тыю, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), муниципаль хезмәт күрсәтү максатыннан муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, шул исәптән автоматлаштырылган режимда эшкәртүгә үземнең ризалыгымны, шулай ук мин вәкиле булып торган затның ризалыгын раслыйм.

Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча ______________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

_______________ ___________________ ( _________________)

(дата) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

2 нче кушымта

# Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге блок-схемасы



3 нче кушымта

Читтән торып эш урыннары исемлеге һәм документларны кабул итү графигы

| № т/б | Читтән торып эш урынының урнашу урыны | Хезмәт күрсәтә торган торак пунктлар | Документларны кабул итү графигы |
|---|---|---|---|
| 1. | Бело-Безводное ав., Юбилей ур., 13 нче йорт | Бело-Безводное ав., Местечко Раифа п., Садовый п. | . Дүшәмбе, чәршәмбе, җомга: 08:00 – 15:00 Төшке аш вакыты: 12:00 – 13:00 |
| 2. | Осиново авылы, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 3 нче йорт | Осиново авылы, Яңа Тура авылы, Ремплер авылы, Воронино авылы, Новониколаевский п. | |
| 3. | Октябрь п., Беренче Май ур., 2 нче йорт | Октябрь п., Ореховка авылы | |
| 4. | Норлат ав., Гагарин ур., 46 нчы йорт | Норлаты авылы, Косякау авылы, Албаба авылы, Булатово авылы, Рязаново авылы, Татар Исламы авылы, Албаба п., Прибой п. | |
| 5. | Олы Җәке ав., Мәктәп ур., 1 нче йорт | Олы Җәке авылы, Уразлы авылы, Каратмән авылы, Никольский авылы, Үтәнгеш авылы | |
| 6. | Олы Карагуҗа авылы, Тынычлык ур., 41 нче йорт | Олы Карагуҗа авылы, Олы Күлбаш авылы, Кече Карагуҗа авылы, Синтәк авылы, Чирүчи авылы | |
| 7. | Большие Ключи авылы, Волостнов ур., 16а йорты | Большие Ключи авылы, Малые Ключи авылы, Ивановское авылы, Маевка авылы, Соловьевка авылы, Светлое Озеро п. | |
| 8. | Әйшә авылы, Яшьләр ур., 60 нчы йорт | Әйшә авылы, Ильинское авылы, Кызыл Яр авылы, Сафоново авылы, Успенка авылы, Нарат п. | |
| 9. | Мамадыш-Әкил ав., Ленин ур., 50 нче йорт | Мамадыш-Әкил авылы, Панау авылы, Рус Танае авылы, Татар Танае авылы | |
| 10. | Карамалы Тау штп, Беренче Май ур., 70 нче йорт | Карамалы Тау штп, Олы Ходяш авылы, Бритвино авылы, Ходяш п, Луговой п, Кече Ходяш п., | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Мизиново авылы, Исак авылы, Протопоповка авылы | |
| 11. | Васильево штп., Ирек ур., 1 нче йорт | Васильево штп | |

4 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесенә
______________________________

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

**Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында түбәндәгеләрне хәбәр итәм**
__________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтүнең атамасы)

Язылган:___________________________________________________________
__________________________________________

Дөрес белешмәләр:_________________________________________________
________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны беркетәм:

1.

2.

3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны:

электрон документны_______ E-mail адресына җибәрү юлы белән

- расланган күчермә рәвешендә кәгазь чыганакта почта аша ____________________________________________________________ адресына җибәрүегезне сорыйм.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, тыю, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль

хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), муниципаль хезмәт күрсәтү максатыннан муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, шул исәптән автоматлаштырылган режимда эшкәртүгә үземнең ризалыгымны, шулай ук мин вәкиле булып торган затның ризалыгын раслыйм.

Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча ______________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

_______________ ___________________ ( __________________)

(дата) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Кушымта
(белешмә мәгълүмат)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Зеленодольск муниципаль районы Советы**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы | (84371)42513 | Sovet.ZMR@tatar.ru |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 8(84371)40576 | ispolkom.zmr@tatar.ru |

«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы » муниципаль учреждениесе

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Палата җитәкчесе | 8(84371)42107 | Palataizo@yandex.ru |
| Палата белгече | 8(84371) 57982/57827 | Palataizo@yandex.ru |

2 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 23 маендагы
1313 номерлы карарына

.

**Җир кишәрлеген даими (срогы чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) муниципаль милектәге җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү(алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү, хезмәт күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Регламентның гамәлдә булуы Зеленодольск муниципаль районы территориясендәге муниципаль милектәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә кагыла.

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар (алга таба - мөрәҗәгать итүче): Россия Федерациясе Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән органнар һәм учреждениеләр (1 нче кушымта).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы - «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (алга таба - Палата).

Документларны кабул итү «Зеленодольск муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» муниципаль бюджет учреждениесендә (алга таба - КФҮ) башкарыла.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты.

Эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр билгеләнә.

Палатаның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 38 нче йорт

Эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

кабул итү көне: сишәмбе: 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр билгеләнә.

Палатаның белешмә телефоны: 4-21-07 (кабул итү бүлмәсе).

Керү шәхесне таныклый торган документлар буенча

Керү ирекле, алдан язылу таләп ителми.

КФҮ урнашкан урын: Зеленодольск шәһәре, Беренче Май ур., 14 нче йорт

Эш графигы:

дүшәмбе, чәршәмбе, шимбә, якшәмбе 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

сишәмбе, пәнҗешәмбе көнне 10.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр (2016 елның 07 сентябреннән сишәмбе көннәрендә 10:00 дән 20:00 гә кадәр);

җомга 7.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә (алга таба- «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындаЗеленодольск муниципаль районы сайтының (алга таба – Зеленодольск муниципаль районы сайты) адресы:http://zelenodolsk.tatarstan.ruПалатаның электрон адресы: Palataizo@yandex.ru к

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүматны түбәндәге ысуллар белән алырга мөмкин:

1) Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Палата биналарында урнашкан муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт күрсәтү турында белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша Зеленодольск муниципаль сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) ;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https:/ www.gosuslugi.ru);

5) Палатада:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон буенча;

язмача (шул исәптән ЭЦП таныклаган электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә - кәгазь саклагычта почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.4. Палата белгече мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматны Зеленодольск муниципаль районы сайтында һәм Палата биналарында мәгълүмат стендларында урнаштыруны тәэмин итә.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Граждан кодексының 1994 елның 30 декабрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба - РФ ГК) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, ст.3301);

Россия Федерациясенең 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы җир кодексы (алга таба - РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 29.10.2001, №44, 4147ст.);

Татарстан Республикасы Җир кодексы белән 1998 елның 10 июлендәге 1736 номерлы («Республика Татарстан, 22.01.2005, №10-11);

2001 елның 25 октябрендәге "Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында" 137-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 137-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия газетасы, №95, 05.05.2006) (алга таба - 59-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 06.10.2003, №40, 3822 ст.);

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004) (алга таба - 45-ТРЗ номерлы ТР Законы);

«Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Россия Икътисади үсеш министрлыгының "Мөрәҗәгать итүченең сату уздырмыйча җир кишәрлеге сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлеген раслау турында" 2015 елның 12 гыйнварындагы 1 нче боерыгы (алга таба 1 нче боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.02.2015);

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск

муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав) («Зеленодольская правда», №№253-256, 31.12.2005 ел);

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 1 февралендәге 39 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе турында нигезләмә (алга таба – Палата турында нигезләмә) («Зеленодольская правда», № 40, 01.03.2006);

«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесенең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән.

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, мөрәҗәгать итүчеләргә консультацияләр бирү тәрәзәсе;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән белешмәләрнең (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең) алар нигезендә белешмәләр кертелә торган документлардагы белешмәләргә тәңгәл килмәвенә китергән хата (басма язу хатасы, ялгыш, грамматик яки арифметик хата яки шуңа охшаш хата);

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза астында (алга таба - гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 п.). Гариза стандарт бланкта тутырыла (2 нче кушымта).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка куелган таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күсәтүнең атамасы | Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү | РФ ҖК, Палата турындагы нигезләмә<br>. |
| 2.2. Җирле үзидарәнең муниципаль хезмәтне турыдан-туры күрсәтүче башкарма-күрсәтмә органы исеме | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет),<br>«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (алга таба - Палата) | РФ Җир кодексының 3.2 статьясы,<br>ТР ЗК 5 статьясы,<br>Палата турында нигезләмә |
| Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Җир кишәрлеген бирү турында, җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат. | Россия Федерациясе Җир кодексы |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Гариза килгән көннән алып утыз көннән дә артык булмаган вакыт эчендә җир кишәрлеген даими (срогы чикләнмәгән) файдалануга бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү | РФ ЗК 39.17 ст.5 п. |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яисә | 1) Гариза;<br>2) шәхесне таныклый торган документлар; | Россия Федерациясе Җир кодексы |

| | | |
|---|---|---|
| башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең төгәл исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | 3) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил булса);<br>4) Юридик затның гамәлгә кую документлары күчермәләре<br>5) Күчемсез милек объектына мөрәҗәгать итүченең хокукларын билгели торган документлар, әгәр аңа хокук Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса;<br>Күчемсез милек объектын урнаштыру урынын алдан килештерү турында карар булганда:<br>1) Гариза;<br>2) шәхесне таныклый торган документлар;<br>3) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил булса);<br>4) Юридик затның гамәлгә кую документлары күчермәләре.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелә торган өстәмә документлар исемлеге, хезмәт күсәтүне алучының категориясенә карап, 3 нче кушымтада китерелгән<br>Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда түбәндәге ысулларның берсе тарафыннан бирелергә (җибәрелергә) мөмкин: | 1 нче боерык |

| | | |
|---|---|---|
| | шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>заказлы почта юлламасы белән тапшыру турында хәбәрнамә белән.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; дәүләт | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар исемлеге, хезмәт күрсәтүләрне алучылар категориясенә карап, 3 нче кушымтада күрсәтелгән<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | 1 нче боерык |

| | | |
|---|---|---|
| органы, җирле үзидарә органы йә шушы документлар белән эш итүче оешма | | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә торган һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган гамәлгә ашыра торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | «Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» муниципаль бюджет учреждениесе;<br>Башкарма комитет җитәкчесе | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) документларның тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;<br>2) Күрсәтелгән документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага теркәлгән документларда алдан әйтелмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлап була алмый торган җитди бозылулар булу;<br>4) Документлар тиешле булмаган органга тапшыру | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир кишәрлеге бирү турында гариза белән җир законнары нигезендә җир кишәрлеген торглар | Әлеге Регламент белән билгеләнә<br>Ст.39.16 ЗК РФ |

| | | |
|---|---|---|
| | үткәрмичә сатып алу хокукына ия булмаган кеше мөрәҗәгать итүе<br>2)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлеккә мирас итеп алынган милек яки аренда хокукында бирелгән булса, җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге хокукларга ия булучы мөрәҗәгать иткән яисә җир кишәрлеген РФ Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пункты нигезендә бирү турында гариза бирелгән очраклардан тыш;<br>3) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмага яшелчәчелек, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару яисә индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирелгән, моңа әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзасы яисә әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзасы гаризасы белән мөрәҗәгать итү очраклары керми, әгәр җир кишәрлеге гомуми файдаланудагы мөлкәткә керсә;<br>4) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарга яки юридик затларга караган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеш тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында яисә җир кишәрлегендә РФ Җир кодексының 39.36 статьясындагы 3 пунктында каралган объект урнаштырылган очраклардан тыш, | |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм бу җир кишәрлегеннән файдалану рөхсәт ителгән файдалану нигезендә каршылык тудырмый яки бу биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса;<br>5)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеш тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында яисә җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән җир кишәрлегендә урнаштырылган очраклардан тыш, әлеге биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса;<br>6) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең әйләнештән алынган булуы яисә әйләнештә булуы чикләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокукта аны бирү рөхсәт ителмәү;<br>7) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган була, әгәр мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген милеккә бирү, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса яисә җир кишәрлеген арендага бирү , җир кишәрлеген резервлау турындагы карар гамәлдә булу срогыннан арткан | |

| | | |
|---|---|---|
| | вакытка түләүсез файдалану турында гариза белән мөрәҗәгать итсә, резервлау максатларында җир кишәрлеге бирү очрагыннан тыш;<br>8) җир кишәрлеге җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан,җир кишәрлеге бирү турында гариза белән шундый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, алардагы бүлмәләр, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы яки шундый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>9) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелешле территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән, мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>10)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документациягә ярашлы рәвештә федераль | |

| | | |
|---|---|---|
| | әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлегеннән төзелгән, җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки күрсәтелгән объектларны төзү буенча әлеге затның йөкләмәләрен күздә тоткан төзелеш территориясен үстерү турында шартнамә төзегән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>11) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турында хәбәр Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 19 пункты нигезендә урнаштырылган;<br>12) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктының 6 пунктчасында каралган аны сату яки аны арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру турында гариза керде, мондый җир кишәрлеге РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктындагы 4 пунктчасы һәм вәкаләтле орган нигезендә төзелгән очракта, мондый җир кишәрлеге РФ Җир кодексының 39.11 статьясының 8 пунктында каралган нигезләрдә әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән булса;<br>13)җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак | |

| | | |
|---|---|---|
| | төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, дача хуҗалыгы яисә аның крестьян (фермер) хуҗалыгы өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәр басылып чыккан һәм урнаштырылган;<br>14)җир кишәрлеген рөхсәт ителгән куллану җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген куллану максатларына туры килми, территорияне планлаштыруның расланган проектына ярашлы рәвештә линия объектын урнаштыру очракларыннан тыш;<br>15) соралган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм иминлек ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча кулланылмый торган җир кишәрлекләре исемлегенә кертелмәгән, әгәр җир кишәрлеген Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пункты нигезендә бирү турында гариза бирелгән булса;<br>16) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешманың җир кишәрлеген яшелчәчелек, бакчачылык алып бару өчен бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы федераль закон нигезендә билгеләнгән иң чик күләмнән артып китә;<br>17)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль планлаштыруның расланган документларына һәм (яки) территорияне планлаштыру буенча документациягә ярашлы рәвештә федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге | |

| | | |
|---|---|---|
| | объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>18) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бинаны, корылманы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән әлеге бинаны, корылманы төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>19) хокукларның билгеләнгән рәвешендә җир кишәрлеге бирү рөхсәт ителми;<br>20) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән куллану төре билгеләнмәгән;<br>21) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге билгеле бер җирләр категориясенә кертелмәгән;<br>22) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата, гамәлдә булу срогы тәмамланмаган килеш бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать иткән;<br>23)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган һәм гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү максаты мондый җир кишәрлеген тартып алган максатларга туры килми , | |

| | | |
|---|---|---|
| | мондый җир кишәрлегендә урнашкан күп фатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану сәбәпле, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир кишәрлекләреннән тыш;<br>24) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;<br>25) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасында, шундый җир кишәрлеге барлыкка килгән территорияне ызанлау проектында яки урман кишәрлекләренең проект документациясендә күрсәтелгән мәйданнан ун проценттан артыграк. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | Әлеге Регламент белән билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Муниципаль хезмәттән файдалану турында гариза бирү вакыты, чират булган очракта, 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризасын теркәү, шул исәптән электрон формада теркәү срогы | Гариза килгәннән соң өч көн эчендә | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм кабул итү урыннарына таләпләр, шул исәптән күрсәтелгән объектларның инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Кәгазьдә гариза Башкарма комитетка, КФҮкә, эш графигына туры китереп читтән торып эш урынына бирелә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла:<br>һава кондиционерлау системасы;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документларны рәсмиләштерү өчен җиһазлар;<br>мәгълүмат стендлары белән;<br>инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү мөмкинлеген булдыра торган чаралар һәм җиһазлар белән. | Әлеге Регламент белән билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең уңайлылык һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләре саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыннарында муниципаль хезмәт күрсәтү алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр аша | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Палата бинасы җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашкан;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;<br>инвалидларга башка кешеләр белән беррәттән муниципаль хезмәт алуга комачаулаучы каршылыкларны җиңәргә ярдәм күрсәтү;<br>сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;<br>алып йөртүче этне Палата бинасына кертүгә рөхсәт;<br>Мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән билгеләнә:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларга документларны тапшырганда чират булмавы ;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | Әлеге Регламент белән билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| | булмау .<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазифаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла. Аралашу дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба - КФҮ) , КФҮ читтән торып эш урыннарында күрсәтелгәндә консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм тапшыруны КФҮ белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан https://www.gosuslugi.ru сайтында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, КФҮ сайтында алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү законда каралган очракта, гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) яисә Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (https:/ www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү срогы, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә эзлекле гамәлләр тасвирламасы

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр булдыру һәм җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге блок-схемасы 4 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр күрсәтү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче Палатага шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма гариза тапшыра һәм документларны шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә тапшыра. Документлар читтән торып эш урыны аша бирелергә мөмкин. Читтән торып эш урыннары исемлеге 5 нче кушымтада китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Интернет кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада кабул ителгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2.КФҮ белгече яки Башкарма комитет белгече, гаризалар кабул итүне алып баручы, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышанычнамә белән эш иткән очракта);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә (документларның күчермәләрен тиешенчә ясау, документларда төзәтүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка килештерелмәгән төзәтүләрнең булмавын).

Кисәтүләр булмаган очракта, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм аны махсус журналда терки;

мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне башкару датасы һәм вакыты турында билге куелган документлар исемлегенең күчермәсен тапшыра;

Гаризаны Палата җитәкчесенә карауга җибәрү.

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, КФҮ белгече йә Башкарма комитет белгече, документларны кабул итүне алып баручы, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар барлыгы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язма аңлатма белән документларны кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

гаризаны һәм документларны 15 минут эчендә кабул итү;

гаризаны теркәү, гариза килгәннән соң өч көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Палата җитәкчесе каравынаҗибәрелгән яисә мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Палата җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга юллау.

3.4.1. Палата белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә шушы Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турындагы рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә, соратып алына торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса, документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Палатага җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне әзерләү һәм аның нәтиҗәсен бирү

3.5.1. Палата белгече кергән документлар (белешмәләр) нигезендә шушы Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

3.5.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Палата белгече, баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли һәм Палата җитәкчесенә җибәрә.

Палата җитәкчесе хатны карый һәм имзалый, хат теркәү өчен Башкарма комитетның гомуми бүлегенә җибәрелә.

Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгече хатны терки һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган һәм теркәлгән хат.

3.5.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Палата белгече:

- җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында Башкарма комитет Карары проектын әзерли, (алга таба - Карар проекты);
- Карар проектын Палата җитәкчесенә (ул вәкаләт биргән затка) килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы өч көн дәвамында гамәлгә ашырыла;
- Карар проектын «ЗМР юридик бюросы» МБУ килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы алты көн дәвамында гамәлгә ашырыла;
- Карар проектын Башкарма комитет җитәкчесенә имзага җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палата җитәкчесе һәм «ЗМР юридик бюросы» МБУ белән килештерелгән, Башкарма комитет җитәкчесенә (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) имза салуга юнәлтелгән Карар проекты.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура соралган документлар (белешмәләр) керүнең тугыз көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Башкарма комитет җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат) карарны имзалый һәм аны Башкарма комитет мөһере белән таныклый. Имзаланган карар Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгеченә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура раслауга карар проекты керүнең өч көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган Карар.

3.5.3. Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгече:

- Баш тарту турында карарны яки хатны терки;

Палатага җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура теркәлүгә Карар проекты кабул ителгән көннән алып бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән карар.

3.5.4. Палата белгече:

Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән Карар яисә баш тарту турында хат бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар кире кагу йә Карар турында теркәлгән хат кергән көннән алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.5.5. Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән Карар яки баш тарту турындагы хатны бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

- муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында Карарны яисә хатны бирү - 15 минут эчендә, чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне;

- мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) хатны алу өчен Палатага махсус рәвештә килү мөмкин түгеллеге турында хәбәр иткән очракта,почта аша хат белән баш тарту турында хатны җибәрү -әлеге Регламентның 3.5.4 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә .

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында тапшырылган Карар яисә хат.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Палата белгече:

карарларны теркәү журналында Башкарма комитет җитәкчесе кул куйган Карарны терки;

мөрәҗәгать итүчегә Карарны кул куйдырып бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән Карар.

3.7. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.7.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.7.2. Муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәк аша күрсәтү күпфункцияле үзәкнең билгеләнгән тәртиптә расланган хезмәт регламенты нигезендә башкарыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәт алуга КФҮдән документлар килгәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3 - 3.6 пунктлары нигезендә башкарыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документта техник хаталар ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Палатага түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (6 нчы кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган техник хаталы документны;

техник хаталар булуны дәлилли торган, юридик көчкә ия документларны.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырыла.

3.8.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итә, гариза белән кушымта итеп бирелгән документларны терки һәм аларны Палатага тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Комитетның җаваплы белгеченә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатларында административ Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, һәм мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен кире алып, имза куйдырып, мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) төзәтмәләр кертелгән документны тапшыра яисә мөрәҗәгать итүче адресына, мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган

документның төп нөсхәсен Палатага тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта кулланып) хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыклангannan соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

**Муниципаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары**

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларга виза салу тора;

2) эш алып баруны билгеләнгән тәртиптә тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатендәге мәсьәләләр карап тикшерелергә мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр кылуга контроль  һәм карарлар кабул итү максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы Палата рәисе, шулай ук Палата белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазифаи затлар исемлеге җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрдәнләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланса, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре вакытында карап тикшерелмәве өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм кылынган гамәлләр (гамәл кылмау) өчен закон белән билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору муниципаль хезмәт күрсәткәндә Палата эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять итүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар Палатаның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре Палаткага, Башкарма комитетына яисә Муниципаль берәмлек советына судка кадәр тәртиптә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәттән файдалану турында мөрәҗәгатен теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Зеленодольск муниципаль районының башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма

хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять язма формада кәгазь чыганакта яки электрон формада бирелә.

Шикаятьне почта аша, КФҮ аша, "Интернет" челтәреннән файдаланып, http://uslugi.tatar.ru рәсми сайты, Зеленодольск муниципаль районы сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/), шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән алып унбиш көн эчендә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта - аны теркәгән көннән алып биш көн эчендә..

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтә торган органның, хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәренең исем-атамасы;

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр - физик зат яки исеме, мөрәҗәгать итүче - юридик зат урнашкан урын, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап бирелергә тиешле почта адресы турында белешмәләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда язылган хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа беркетелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять, аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы зат тарафыннан, имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Палата җитәкчесе (Башкарма комитет җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кабул ителгән карарныгамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән түләтү каралмаган

акчаларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару формасында, шулай ук башка формаларда да шикаятьне канәгатьләндерә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап юллана.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазифаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

1 нче кушымта

Россия Федерациясе Җир кодексыннан өземтә

39.9 статья. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү

2. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга түбәндәгечә бирелә:

1) дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына;

2) дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә (бюджет, казна, автоном);

3) казна предприятиеләренә;

4) үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Россия Федерациясе президентларының тарихи мирас үзәкләренә.

2 нче кушымта

__________________________________________

(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)

_________________________________________ (физик затлар өчен-фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)

_____________________________________________

(юридик затлар өчен-атамасы, урнашу урыны, оештыру-хокукый рәвеше, ЕГРЮЛ, ОГРН дәүләт теркәве турында белешмәләр)

_____________________________________________

(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

## Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында гариза

Сездән _________________________________________________нигезендә

(РФ Җир кодексының 39.9 ст.2 пунктында каралганнардан нигезе күрсәтелә).

__________________________________________________________өчен бирүне сорыйм.

(җир кишәрлегеннән файдалану максаты күрсәтелә)

адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге ____________ кв.м., кадастр номеры ______________________, рөхсәт ителгән файдалану төре белән, җирләр категориясеннән __________________________ муниципаль район (шәһәр округы), торак пункт_________________ ур.________________ йорт. даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, торглар үткәрмичә.

Өстәмә белешмәләр (түбәндәге шартлар булганда тутырыла):

______________________________________________________________________

җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеге урынына бирелгән очракта, дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеген алу турында карар реквизитлары;

______________________________________________________________________

әгәр җир кишәрлеге әлеге документта һәм (яисә) әлеге проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелгән булса, территориаль планлаштыру документын һәм (яисә) территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар реквизитлары;

______________________________________________________________________

сорала торган җир кишәрлеге төзелгән яисә аның чикләре әлеге карар нигезендә төгәлләштерелгән очракта, җир кишәрлеген алдан килештерү турында карар реквизитлары.

Гаризага түбәндәге документлар (сканерланган күчермәләр) теркәлә:

Физик затлар:

1) Шәхесне раслаучы документ күчермәсе (граждан өчен);

2) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкиле булса);

Юридик затлар:

1) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил гамәлдә булса);

*Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, тыю, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), муниципаль хезмәт күрсәтү максатыннан муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, шул исәптән автоматлаштырылган режимда эшкәртүгә үземнең ризалыгымны, шулай ук мин вәкиле булып торган затның ризалыгын раслыйм.*

*Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.*

*Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча* ______________________ *телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.*

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | ___________ | ______________________________ |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.Ат. и.) |

3 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлегеннән өземтә

| № т/б | Торглар үткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезләре | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алу хокукын раслый торган һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага теркәлә торган документлар<1> |
|---|---|---|---|---|---|
| 62. | Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасы | Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга | Дәүләт хакимияте органы | Дәүләт хакимияте органнарының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге | Әлеге Исемлектә каралган, җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген бирүгә хокукын раслый торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | хәбәрнамә |
| 63. | Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасы | Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга | Җирле үзидарә органы | Җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен башкару өчен кирәкле җир кишәрлеге | Әлеге Исемлектә каралган, җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген бирүгә хокукын раслый торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә |
| 64. | Җир кодексының 39.9 статьясы 2 пунктының 2 пунктчасы | Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга | Дәүләт яки муниципаль (бюджет, казна, автоном) учреждение | Дәүләт яки муниципаль (бюджет, казна, автоном) учреждение эшчәнлеген башкару өчен кирәкле җир кишәрлеге | Әлеге Исемлектә каралган, җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген бирүгә хокукын раслый торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | *Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә<br><br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 65. | Җир кодексының 39.9 статьясы 2 пунктының 3 пунктчасы | Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга | Казна предприятиесе | Казна предприятиесе эшчәнлеген башкару өчен кирәкле җир кишәрлеге | Әлеге Исемлектә каралган, җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген бирүгә хокукын раслый торган документлар<br><br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br><br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә<br><br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 66. | Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктының 4 пунктчасы | Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга | Россия Федерациясе президентларының үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан тарихи мирас үзәге | Үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Россия Федерациясе президентларының тарихи мирас үзәге эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге | Әлеге Исемлектә каралган, җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген бирүгә хокукын раслый торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |

<1> Документлар чынлыкта (күчермәдә, әгәр документлар һәркем файдалана алырлык булса) йә башкарма хакимият органының яисә җирле үзидарә органының җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризаны кабул итүче вазыйфаи заты тарафыннан таныклана торган күчермәләрендә тапшырыла (җибәрелә).

<2> Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, N 44, 4147 ст., 2014, N 26, 3377 ст.

<3> "*"символ белән билгеләнгән документлар дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре (алга таба - вәкаләтле орган) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән эш итүгә вәкаләтле орган тарафыннан соратып алына.

4 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы



5 нче кушымта

Читтән торып эш урыннары исемлеге һәм документларны кабул итү графигы

| № т/б | Читтән торып эш урынының урнашу урыны | Хезмәт күрсәтә торган торак пунктлар | Документлар кабул итү графигы |
|---|---|---|---|
| 1. | Бело-Безводное ав., Юбилей ур., 13 нче йорт | Бело-Безводное ав., Местечко Раифа п., Садовый п. | Дүшәмбе, чәршәмбе, җомга: 08:00 – 15:00 Төшке аш вакыты: 12:00 – 13:00 |
| 2. | Осиново авылы, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 3 нче йорт | Осиново авылы, Яңа Тура авылы, Ремплер авылы, Воронино авылы, Новониколаевский п. | |
| 3. | Октябрь п., Беренче Май ур., 2 нче йорт | Октябрь п., Ореховка авылы | |
| 4. | Норлат ав., Гагарин ур., 46 нчы йорт | Норлаты авылы, Косякау авылы, Албаба авылы, Булатово авылы, Рязаново авылы, Татар Исламы авылы, Албаба п., Прибой п. | |
| 5. | Олы Җәке ав., Мәктәп ур., 1 нче йорт | Олы Җәке авылы, Уразлы авылы, Каратмән авылы, Никольский авылы, Үтәнгеш авылы | |
| 6. | Олы Карагуҗа авылы, Тынычлык ур., 41 нче йорт | Олы Карагуҗа авылы, Олы Күлбаш авылы, Кече Карагуҗа авылы, Синтәк авылы, Чирүчи авылы | |
| 7. | Большие Ключи авылы, Волостнов ур., 16а йорты | Большие Ключи авылы, Малые Ключи авылы, Ивановское авылы, Маевка авылы, Соловьевка авылы, Светлое Озеро п. | |
| 8. | Әйшә авылы, Яшьләр ур., 60 нчы йорт | Әйшә авылы, Ильинское авылы, Кызыл Яр авылы, Сафоново авылы, Успенка авылы, Нарат п. | |
| 9. | Мамадыш-Әкил ав., Ленин ур., 50 нче йорт | Мамадыш-Әкил авылы, Панау авылы, Рус Танае авылы, Татар Танае авылы | |
| 10. | Карамалы Тау штп, Беренче Май ур., 70 нче йорт | Карамалы Тау штп, Олы Ходяш авылы, Бритвино авылы, Ходяш п, Луговой п, | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Кече Ходяш п., Мизиново авылы, Исак авылы, Протопоповка авылы | |
| 11. | Васильево штп., Ирек ур., 1 нче йорт | Васильево штп | |

6 нчы кушымта

«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесенә
____________________________

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

**Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында түбәндәгеләрне хәбәр итәм**
__________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтүнең атамасы)

Язылган:_________________________________________________________________
________________________________________

Дөрес белешмәләр:________________________________________________
___________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны беркетәм:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны:

электрон документны_______ E-mail адресына җибәрү юлы белән

- расланган күчермә рәвешендә кәгазь чыганакта почта аша _____________________________________________________________ адресына җибәрүегезне сорыйм.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, тыю, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), муниципаль хезмәт күрсәтү максатыннан муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, шул исәптән автоматлаштырылган режимда эшкәртүгә үземнең ризалыгымны, шулай ук мин вәкиле булып торган затның ризалыгын раслыйм.

Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча ______________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

_______________ __________________ ( _________________)

(дата) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Кушымта
(белешмә мәгълүмат)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Зеленодольск муниципаль районы Советы**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы | (84371)42513 | Sovet.ZMR@tatar.ru |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 8(84371)40576 | ispolkom.zmr@tatar.ru |

«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы » муниципаль учреждениесе

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Палата җитәкчесе | 8(84371)42107 | Palataizo@yandex.ru |
| Палата белгече | 8(84371) 57982/57827 | Palataizo@yandex.ru |

3 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 23 маендагы
1313 номерлы карарына

**Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү, хезмәт күрсәтү)стандартын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Регламентның гамәлдә булуы Зеленодольск муниципаль районы территориясендәге муниципаль милектәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә кагыла.

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар (алга таба - мөрәҗәгать итүче): Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясында күрсәтелгән физик һәм юридик затлар (1 нче кушымта).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы - «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (алга таба - Палата).

Документларны кабул итү «Зеленодольск муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» муниципаль бюджет учреждениесендә (алга таба - КФҮ) башкарыла.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты.

Эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр билгеләнә.

Палатаның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 38 нче йорт

Эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

кабул итү көне: сишәмбе: 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр билгеләнә.

Палатаның белешмә телефоны: 4-21-07 (кабул итү бүлмәсе).

Керү шәхесне таныклый торган документлар буенча

Керү ирекле, алдан язылу таләп ителми.

КФҮ урнашкан урын: Зеленодольск шәһәре, Беренче Май ур., 14 нче йорт

Эш графигы:

дүшәмбе, чәршәмбе, шимбә, якшәмбе 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

сишәмбе, пәнҗешәмбе көнне 10.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр (2016 елның 07 сентябреннән сишәмбе көннәрендә 10:00 дән 20:00 гә кадәр);

җомга 7.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә (алга таба- «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындаЗеленодольск муниципаль районы сайтының (алга таба – Зеленодольск муниципаль районы сайты) адресы:http://zelenodolsk.tatarstan.ruПалатаның электрон адресы: Palataizo@yandex.ru к

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүматны түбәндәге ысуллар белән алырга мөмкин:

1) Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Палата биналарында урнашкан муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт күрсәтү турында белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша Зеленодольск муниципаль сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) ;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https:/ www.gosuslugi.ru);

5) Палатада:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон буенча;

язмача (шул исәптән ЭЦП таныклаган электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә - кәгазь саклагычта почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.4. Палата белгече мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматны Зеленодольск муниципаль районы сайтында һәм Палата биналарында мәгълүмат стендларында урнаштыруны тәэмин итә.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Граждан кодексының 1994 елның 30 декабрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба - РФ ГК) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);

Россия Федерациясенең 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы җир кодексы (алга таба - РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 29.10.2001, №44, 4147ст.);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 06.10.2003, №40, 3822 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 27 ноябрендәге«Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын әзерләү таләпләрен раслау турында, территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын электрон документ рәвешендә әзерләгәндә территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы, әзерләү кәгазь чыганакта документ рәвешендә башкарыла торган территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы рәвешләрен раслау турында» 762 номерлы боерыгы белән Россия Федерациясе (алга таба-762 номерлы боерык)(Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru 18.02.2015);

Россия Икътисади үсеш министрлыгының "Мөрәҗәгать итүченең сату уздырмыйча җир кишәрлеге сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлеген раслау турында" 2015 елның 12 гыйнварындагы 1 нче боерыгы (алга таба 1 нче боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.02.2015);

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 45-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004);

«Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав) («Зеленодольская правда», №№253-256, 31.12.2005 ел);

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 1 февралендәге 39 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе турында нигезләмә (алга таба – Палата турында нигезләмә) («Зеленодольская правда», № 40, 01.03.2006);

«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесенең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән.

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, мөрәҗәгать итүчеләргә консультацияләр бирү тәрәзәсе;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән белешмәләрнең (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең) алар нигезендә белешмәләр кертелә торган документлардагы белешмәләргә тәңгәл килмәвенә китергән хата (басма язу хатасы, ялгыш, грамматик яки арифметик хата яки шуңа охшаш хата);

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза астында (алга таба - гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 п.). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 нче кушымта).

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны - муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, мөрәҗәгать итүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе;

техник хата − муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан кертелгән һәм документка (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кергән документлардагы белешмәләрнең тәңгәл килмәвенә китергән хата (описка, басма хата, грамматик яки арифметик хата яисә шундый хата)

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 нче пункт). Гариза стандарт бланкта тутырыла (2 нче кушымта).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка куелган таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күсәтүнең атамасы | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү | РФ ЗК. 39.5 ст., 39.17 ст. |
| 2.2. Җирле үзидарәнең турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтә торган башкару-оештыру органы исеме | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет),<br>«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (алга таба - Палата) | РФ Җир кодексының 3.2 статьясы,<br>ТР ЗК 5 статьясы,<br>Палата турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Җир кишәрлеге бирү турында карар, җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ Җир кодексының 39.1 ст.1 п. |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген дә исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Гариза кергән көннән алып утыз көн эчендә | РФ ЗК 39.17 ст.5 п. |
| 2.5. Законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль | 1) Гариза;<br>2) шәхесне таныклый торган документлар;<br>3) Мөрәҗәгать итүче вәкиленең, җир кишәрлеген | Россия Федерациясе Җир кодексы |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәт күрсәтү өчен кирәкле, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | алдан килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>4) мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очракта, чит ил дәүләт законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәве турындагы документларны рус теленә таныкланган тәрҗемәсе;<br>5) Гражданнар тарафыннан оештырылган коммерцияле булмаган оешма тарафыннан әзерләнгән җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү яки яшелчәчелек яки бакчачылык алып бару өчен әлеге оешмага түләүсез файдалануга җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән очракта, аның әгъзалары исемлеге.<br>6) Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алу хокукын раслаучы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән исемлектә каралган документлар, вәкаләтле органга ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә тапшырылырга тиешле документлардан тыш (мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә документлар исемлеге, хезмәт күрсәтү алучының категориясенә карап, 3 нче кушымтада китерелгән)<br>Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар | 1 нче боерык |

| | | |
|---|---|---|
| | мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда түбәндәге ысулларның берсе тарафыннан бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>заказлы почта юлламасы белән тапшыру турында хәбәрнамә белән.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар исемлеге, хезмәт күрсәтүләрне алучылар категориясенә карап, 3 нче кушымтада күрсәтелгән<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | 1 нче боерык |

| | | |
|---|---|---|
| тапшыру тәртибе; әлеге документларны үз карамагына алган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | | |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрне күрсәтү өчен норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү таләп ителгән дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | «Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» муниципаль бюджет учреждениесе;<br>Башкарма комитет җитәкчесе | Әлеге Регламент тарафыннан билгеләнә |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) документларның тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;<br>2) тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага теркәлгән документларда алдан әйтелмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлап була алмый торган җитди бозылулар булу;<br>4) Документларны тиешле булмаган органга тапшыру. | Әлеге Регламент тарафыннан билгеләнә |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган. | |

| | | |
|---|---|---|
| яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир кишәрлеге бирү турында гариза белән җир законнары нигезендә җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алу хокукына ия булмаган кеше мөрәҗәгать итүе<br>2)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлеккә мирас итеп алынган милек яки аренда хокукында бирелгән булса, җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге хокукларга ия булучы мөрәҗәгать иткән яисә җир кишәрлеген РФ Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пункты нигезендә бирү турында гариза бирелгән очраклардан тыш;<br>3) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмага яшелчәчелек, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару яисә индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирелгән, моңа әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзасы яисә әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзасы гаризасы белән мөрәҗәгать итү очраклары керми, әгәр җир кишәрлеге гомуми файдаланудагы мөлкәткә керсә;<br>4) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарга яки юридик затларга караган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеш тәмамланмаган корылма) сервитут | РФ ЗК 39.16 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | шартларында яисә җир кишәрлегендә РФ Җир кодексының 39.36 статьясындагы 3 пунктында каралган объект урнаштырылган очраклардан тыш, һәм бу җир кишәрлегеннән файдалану рөхсәт ителгән файдалану нигезендә каршылык тудырмый яки бу биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса;<br>5)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеш тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында яисә җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән җир кишәрлегендә урнаштырылган очраклардан тыш, әлеге биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса;<br>6) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең әйләнештән алынган булуы яисә әйләнештә булуы чикләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокукта аны бирү рөхсәт ителмәү;<br>7) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган була, әгәр мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген милеккә бирү, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану турында гариза белән | |

| | | |
|---|---|---|
| | мөрәҗәгать иткән булса яисә җир кишәрлеген арендага бирү , җир кишәрлеген резервлау турындагы карар гамәлдә булу срогыннан арткан вакытка түләүсез файдалану турында гариза белән мөрәҗәгать итсә, резервлау максатларында җир кишәрлеге бирү очрагыннан тыш;<br>8) җир кишәрлеге җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан,җир кишәрлеге бирү турында гариза белән шундый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, алардагы бүлмәләр, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы яки шундый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>9) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелешле территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән, мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>10)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки | |

| | | |
|---|---|---|
| | төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документациягә ярашлы рәвештә федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлегеннән төзелгән, җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки күрсәтелгән объектларны төзү буенча әлеге затның йөкләмәләрен күздә тоткан төзелеш территориясен үстерү турында шартнамә төзегән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>11) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турында хәбәр Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 19 пункты нигезендә урнаштырылган;<br>12) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктының 6 пунктчасында каралган аны сату яки аны арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру турында гариза керде, мондый җир кишәрлеге РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктындагы 4 пунктчасы һәм вәкаләтле орган нигезендә төзелгән очракта, мондый җир кишәрлеге РФ Җир кодексының 39.11 статьясының 8 пунктында каралган нигезләрдә әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән булса;<br>13)җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, дача хуҗалыгы яисә аның крестьян (фермер) хуҗалыгы өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәр басылып чыккан һәм урнаштырылган;<br>14)җир кишәрлеген рөхсәт ителгән куллану җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген куллану максатларына туры килми, территорияне планлаштыруның расланган проектына ярашлы рәвештә линия объектын урнаштыру очракларыннан тыш;<br>15) соратыла торган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча кулланылмый торган җир кишәрлекләре исемлегенә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кертелмәү, әгәр РФ ЗК 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән булса;<br>16) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешманың җир кишәрлеген яшелчәчелек, бакчачылык алып бару өчен бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы федераль закон нигезендә билгеләнгән иң чик күләмнән артып китә;<br>17)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | планлаштыруның расланган документларына һәм (яки) территорияне планлаштыру буенча документациягә ярашлы рәвештә федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>18) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бинаны, корылманы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә урнаштыру өчен һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге бинаны, корылманы төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>19) хокукларның билгеләнгән рәвешендә җир кишәрлеге бирү рөхсәт ителми;<br>20) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән куллану төре билгеләнмәгән;<br>21) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге билгеле бер җирләр категориясенә кертелмәгән;<br>22) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата, гамәлдә булу срогы тәмамланмаган килеш бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать иткән;<br>23)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | ихтыяҗлар өчен алынган һәм гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү максаты мондый җир кишәрлеген тартып алган максатларга туры килми , мондый җир кишәрлегендә урнашкан күп фатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану сәбәпле, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир кишәрлекләреннән тыш;<br>24) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;<br>25) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасында, мондый җир кишәрлеге барлыкка килгән территорияне ызанлау проектында яки урман кишәрлекләренең урнашуы, чикләре, мәйданы һәм башка сан һәм сыйфат характеристикалары турындагы проект документациясендә күрсәтелгән мәйданнан ун процентран артыграк | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә | Әлеге Регламент тарафыннан билгеләнә |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | Әлеге Регламент тарафыннан билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Муниципаль хезмәттән файдалану турында гариза бирү вакыты, чират булган очракта, 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | Әлеге Регламент тарафыннан билгеләнә |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризасын теркәү, шул исәптән электрон формада теркәү срогы | Гариза килгәннән соң өч көн эчендә | Әлеге Регламент тарафыннан билгеләнә |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларның күрсәтелгән объектлардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә, әлеге хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы | Кәгазьдә гариза Башкарма комитетка, КФҮкә, эш графигына туры китереп читтән торып эш урынына бирелә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла:<br>һава кондиционерлау системасы;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документларны рәсмиләштерү өчен җиһазлар;<br>мәгълүмат стендлары белән;<br>инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү мөмкинлеген булдыра торган чаралар һәм җиһазлар белән. | Әлеге Регламент тарафыннан билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| һәм мультимедиалы мәгълүматны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең уңайлылык һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләре саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыннарында муниципаль хезмәт күрсәтү алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр аша | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Палата бинасы җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашкан;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итеlә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;<br>инвалидларга башка кешеләр белән беррәттән муниципаль хезмәт алуга комачаулаучы каршылыкларны җиңәргә ярдәм күрсәтү;<br>сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;<br>алып йөртүче этне Палата бинасына кертүгә рөхсәт;<br>Мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән билгеләнә:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларга документларны тапшырганда чират булмавы ;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) | Әлеге Регламент тарафыннан билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| | карата шикаятьләр булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр булмау .<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазифаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла. Аралашу дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба - КФҮ) , КФҮ читтән торып эш урыннарында күрсәтелгәндә консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм тапшыруны КФҮ белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан https://www.gosuslugi.ru сайтында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, КФҮ сайтында алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү законда каралган очракта, гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) яисә Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (https:/ | Әлеге Регламент тарафыннан билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| | www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү срогы, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә эзлекле гамәлләр тасвирламасы

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр булдыру һәм җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге блок-схемасы 4 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр күрсәтү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче Палатага шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма гариза тапшыра һәм документларны шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә тапшыра. Документлар читтән торып эш урыны аша бирелергә мөмкин. Читтән торып эш урыннары исемлеге 5 нче кушымтада китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Интернет кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада кабул ителгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2.КФҮ белгече яки Башкарма комитет белгече, гаризалар кабул итүне алып баручы, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышанычнамә белән эш иткән очракта);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә (документларның күчермәләрен тиешенчә ясау, документларда төзәтүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка килештерелмәгән төзәтүләрнең булмавын).

Кисәтүләр булмаган очракта, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм аны махсус журналда терки;

мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне башкару датасы һәм вакыты турында билге куелган документлар исемлегенең күчермәсен тапшыра;

Гаризаны Палата җитәкчесенә карауга җибәрү.

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, КФҮ белгече йә Башкарма комитет белгече, документларны кабул итүне алып баручы, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар барлыгы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язма аңлатма белән документларны кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

гаризаны һәм документларны 15 минут эчендә кабул итү;

гаризаны теркәү, гариза килгәннән соң өч көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Палата җитәкчесе каравынаҗибәрелгән яисә мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Палата җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга юллау.

3.4.1. Палата белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә шушы Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турындагы рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә, соратып алына торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса, документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Палатага җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне әзерләү һәм аның нәтиҗәсен бирү

3.5.1. Палата белгече кергән документлар (белешмәләр) нигезендә шушы Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

3.5.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Палата белгече, баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли һәм Палата җитәкчесенә җибәрә.

Палата җитәкчесе хатны карый һәм имзалый, хат теркәү өчен Башкарма комитетның гомуми бүлегенә җибәрелә.

Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгече хатны терки һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган һәм теркәлгән хат.

3.5.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Палата белгече:

- җир кишәрлеге бирү турында Башкарма комитет карары проектын әзерли (алга таба - Карар проекты);
- Карар проектын Палата җитәкчесенә (ул вәкаләт биргән затка) килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы өч көн дәвамында гамәлгә ашырыла;
- Карар проектын «ЗМР юридик бюросы» МБУ килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы алты көн дәвамында гамәлгә ашырыла;
- Карар проектын Башкарма комитет җитәкчесенә имзага җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палата җитәкчесе һәм «ЗМР юридик бюросы» МБУ белән килештерелгән, Башкарма комитет җитәкчесенә (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) имза салуга юнәлтелгән Карар проекты.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура соралган документлар (белешмәләр) кергән көннән соң тугыз көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Башкарма комитет җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат) карарны имзалый һәм аны Башкарма комитет мөһере белән таныклый. Имзаланган карар Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгеченә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура раслауга карар проекты керүнең өч көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган Карар.

3.5.3. Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгече:

Карарны терки;

Палатага җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура теркәлүгә Карар проекты кабул ителгән көннән алып бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән карар.

3.5.4. Кергән Карар нигезендә Палата белгече:

- җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты проектын әзерли;

- әзерләнгән документ проектын килештерә һәм Палата җитәкчесенә имза куярга җибәрә.

Баш тарту турында хат килгән очракта, әлеге Регламентның 3.5.7 пунктчасында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүчегә карар бирелгән вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзага юнәлтелгән җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты проекты.

3.5.5. Палата җитәкчесе кабул итү-тапшыру актына кул куя һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамлаганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзаланган җир кишәрлегенең кабул итү-тапшыру акты.

3.5.6. Палата белгече:

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән карарны һәм җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актын яки баш тарту турында хатны бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар кире кагу турында теркәлгән хат йә Карар һәм кабул итү-тапшыру акты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.5.7. Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән Карар һәм кул куйдырып җир кишәрлегенең кабул итү-тапшыру акты яки баш тарту турында хатны бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

- муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында Карарны яисә хатны бирү - 15 минут эчендә, чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне;

- мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) хатны алу өчен Палатага махсус рәвештә килү мөмкин түгеллеге турында хәбәр иткән очракта,почта аша хат белән баш тарту турында хатны җибәрү -әлеге Регламентның 3.5.4 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә .

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән Карар һәм җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.6.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6.2. Муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәк аша күрсәтү күпфункцияле үзәкнең билгеләнгән тәртиптә расланган хезмәт регламенты нигезендә башкарыла.

3.6.3. Муниципаль хезмәт алуга КФҮдән документлар килгәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3 - 3.6 пунктлары нигезендә башкарыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документта техник хаталар ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Палатага түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (6 нчы кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган техник хаталы документны;

техник хаталар булуны дәлилли торган, юридик көчкә ия документларны.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырыла.

3.7.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итә, гариза белән кушымта итеп бирелгән документларны терки һәм аларны Палатага тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Палата белгеченә карауга юнәлтелгән гариза.

3.7.3. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатларында административ Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, һәм мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен кире алып, имза куйдырып, мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) төзәтмәләр кертелгән документны тапшыра яисә мөрәҗәгать итүче адресына, мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган документның төп нөсхәсен Палатага тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта кулланып) хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыклангannан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

**Муниципаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары**

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларга виза салу тора;

2) эш алып баруны билгеләнгән тәртиптә тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатендәге мәсьәләләр карап тикшерелергә мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр кылуга контроль һәм карарлар кабул итү максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы Палата җитәкчесе, шулай ук Палата белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазифаи затлар исемлеге җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрдәнләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланса, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре вакытында карап тикшерелмәве өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм кылынган гамәлләр (гамәл кылмау) өчен закон белән билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору муниципаль хезмәт күрсәткәндә Палата эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять итүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар Палатаның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре Палаткага, Башкарма комитетына яисә Муниципаль берәмлек советына судка кадәр тәртиптә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәттән файдалану турында мөрәҗәгатен теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Зеленодольск муниципаль районының башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять язма формада кәгазь чыганакта яки электрон формада бирелә.

Шикаятьне почта аша, КФҮ аша, "Интернет" челтәреннән файдаланып, http://uslugi.tatar.ru рәсми сайты, Зеленодольск муниципаль районы сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/), шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән алып унбиш көн эчендә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта - аны теркәгән көннән алып биш көн эчендә..

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтә торган органның, хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәренең исем-атамасы;

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр - физик зат яки исеме, мөрәҗәгать итүче - юридик зат урнашкан урын, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап бирелергә тиешле почта адресы турында белешмәләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда язылган хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа беркетелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять, аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы зат тарафыннан, имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Палата җитәкчесе (Башкарма комитет җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кабул ителгән карарныгамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән түләтү каралмаган акчаларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару формасында, шулай ук башка формаларда да шикаятьне канәгатьләндерә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап юллана.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазифаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

1 нче кушымта

Россия Федерациясе Җир кодексыннан өземтә

39.5 статья. Дәүләт яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданга яисә юридик затка милеккә түләүсез бирү очраклары

Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданга яисә юридик затка, вәкаләтле орган карары нигезендә, түләүсез милек итеп бирү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

1) төзелеш территориясе чикләрендә төзелгән җир кишәрлеге, аңа карата аның үсеше турында килешү төзелгән затка;

2)дини яки хәйрия билгеләнешендәге биналар яки корылмалар милкендә булган дини оешма җир кишәрлеге, шундый җир кишәрлегендә урнашкан;

3) бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен гражданнар тарафыннан оештырылган коммерциячел булмаган оешмага бирелгән һәм әлеге коммерцияле булмаган оешманың гомуми файдаланудагы милкенә яки федераль законда каралган очракларда әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзаларының гомуми милкенә караган җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлеге;

4) җир кишәрлеге бирелгән көннән соң биш ел узгач гражданинга, әлеге граждан күрсәтелгән чорда рөхсәт ителгән файдалану нигезендә мондый җир кишәрлеген куллану шарты белән, Россия Федерациясе ҖК 39.10 статьясындагы 2 пунктының 6 пунктчасы нигезендә, түләүсез файдалануга бирелә

5) гражданга җир кишәрлеге бирелгән көннән алып биш ел узгач, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 7 пунктчасы нигезендә түләүсез файдалануга җир кишәрлеге бирелгән көннән соң, әлеге граждан күрсәтелгән чорда рөхсәт ителгән файдалану нигезендә файдаланылган һәм муниципаль берәмлектә төп эш урыны буенча һәм Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән белгечлек буенча эшләгән очракта;

6) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнгән очракта һәм тәртиптә өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлеге. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан мондый гражданнар торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торырга тиеш дигән таләп каралырга мөмкин, яисә мондый гражданнарның аларны әлеге исәпкә кую өчен нигезләре булу, шулай ук мондый гражданнарга җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү урынына торак урыннары белән тәэмин итү буенча социаль ярдәмнең башка чараларын, аларның ризалыгы белән, бирү мөмкинлеге билгеләнгән;

7) коммерциягә карамаган оешмаларга федераль законнарда каралган очракларда гражданнарның аерым категорияләренә Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда әлеге статьяның 6 пунктчасында күрсәтелмәгән башка очракларда җир кишәрлеге бирү ;

8) даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында дини оешма биргән һәм авыл хуҗалыгы производствосы өчен билгеләнгән җир кишәрлеге, әлеге оешма Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда.

2 нче кушымта

______________________________________________

(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)

______________________________________________

(физик затлар өчен-фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)

______________________________________________

(юридик затлар өчен-атамасы, урнашу урыны, оештыру-хокукый рәвеше, ЕГРЮЛ, ОГРН дәүләт теркәве турында белешмәләр)

______________________________________________

(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

## Җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү турында гариза

Сездән ______________________________________________нигезендә
(РФ ҖК 39.5 статьясында каралган нигез күрсәтелә).
___________________________________________________________өчен бирүне
(җир кишәрлегеннән файдалану максаты күрсәтелә)
сорыйм.

Җир кишәрлеге мәйданы ___________ рөхсәт ителгән файдалану төре белән кв. м.___________________, җир категориясеннән _______________, адрес буенча урнашкан: ___________ муниципаль районы( шәһәр округы), торак пункт_________________ ур._________________йорт ________ сатуларны үткәрмичә милеккә тәэмин итүегезне сорыйм

Өстәмә белешмәләр (түбәндәге шартлар булганда тутырыла):

______________________________________________________________________

җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеге урынына бирелгән очракта, дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеген алу турында карар реквизитлары;

______________________________________________________________________

әгәр җир кишәрлеге әлеге документта һәм (яисә) әлеге проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелгән булса, территориаль планлаштыру документын һәм (яисә) территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар реквизитлары;

______________________________________________________________________

сорала торган җир кишәрлеге төзелгән яисә аның чикләре әлеге карар нигезендә төгәлләштерелгән очракта, җир кишәрлеген алдан килештерү турында карар реквизитлары.

Гаризага түбәндәге документлар (сканерланган күчермәләр) теркәлә:

Физик затлар:

1) Шәхесне раслаучы документ күчермәсе (граждан өчен);

2) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкиле булса);

Юридик затлар:

1) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил гамәлдә булса);

*Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау,*

*анyклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, тыю, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), муниципаль хезмәт күрсәтү максатыннан муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, шул исәптән автоматлаштырылган режимда эшкәртүгә үземнең ризалыгымны, шулай ук мин вәкиле булып торган затның ризалыгын раслыйм.*

*Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.*

*Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча* ______________________ *телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.*

__________________ ___________ _________________________________

(дата) (имза) (Ф.И.Ат. и.)

3 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүченең торглар үткәрмичә җир кишәрлеген сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлегеннән өземтә

| № т/б | Торглар үткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезләре | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алу хокукын раслый торган һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага теркәлә торган документлар<1> |
|---|---|---|---|---|---|
| 11. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 1 пунктчасы | Милеккә бушлай | Төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән зат | Төзелеш территориясе чикләрендә төзелгән, аңа карата аны үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлеге | Төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРдан (дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре барлыкка килү очракларыннан тыш) яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләр булмау турында БДКМРдан өземтә<br>*Расланган территорияне |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | планлаштыру проекты һәм расланган территорияне ызанлау проекты<br><br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 12. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 2 пунктчасы | Милеккә бушлай | Милкендә дини яки хәйрия билгеләнешендәге биналар яки корылмалар булган дини оешма | Дини яки хәйрия билгеләнешендәге биналар яки корылмалар урнашкан җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең бинага, корылмага хокукын раслаучы (билгели торган) документ, әгәр мондый бинага хокук, корылма БДКМРга теркәлмәгән булса<br><br>Әгәр мондый җир кишәрлегенә хокук БДКМРна теркәлмәгән булса, сорала торган җир кишәрлегенә мөрәҗәгать итүченең хокукларын таныклаучы (билгели торган) документ<br><br>Сорала торган җир кишәрлегендә урнашкан барлык биналар, корылмалар исемлеген үз эченә алган мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүчеләргә) аларның кадастр (шартлы, инвентарь) номерларын һәм адреслы ориентирларын күрсәтеп хәбәр итү<br><br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | *Сорала торган җир кишәрлегендә урнашкан бинаның, корылманың кадрлар паспорты<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына хокуклар турында ЕГРНнан өземтә йә соратыла торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәр итү<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 13. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 3 пунктчасы | Милеккә бушлай | Бакчачылык, яшелчәчелек өчен җир кишәрлеге бирелгән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма | Гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән җир кишәрлеген бакчачылык , яшелчәчелек алып бару өчен биргән һәм коммерциягә карамаган оешманың гомуми | Җир кишәрлеген сатып алу турында коммерциягә карамаган оешма органы карары<br>*Территорияне ызанлауның расланган проекты<br>*Коммерциягә карамаган берләшмә территориясен оештыру һәм төзү проекты (территорияне ызанлау расланган проекты булмаган очракта)<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | файдаланудагы мөлкәтенә караган җир кишәрлеге | БДКМРдан (дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре барлыкка килү очракларыннан тыш) яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләр булмау турында БДКМРдан өземтә<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 14. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 3 пунктчасы | Гомуми милеккә бушлай | Бакчачылык, яшелчәчелек өчен җир кишәрлеге бирелгән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма әгъзалары | Гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән җир кишәрлеген бакчачылык , яшелчәчелек алып бару өчен биргән һәм коммерциягә карамаган оешманың гомуми файдаланудагы мөлкәтенә | Мөрәҗәгать итүченең коммерциягә карамаган оешмада әгъзалыгын раслый торган документ<br>*Территорияне ызанлауның расланган проекты<br>*Коммерциягә карамаган берләшмә территориясен оештыру һәм төзү проекты (территорияне ызанлау расланган проекты булмаган очракта)<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРдан (дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | караган җир кишәрлеге | барлыкка килү очракларыннан тыш) яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләр булмау турында БДКМРдан өземтә<br>*Граждан әгъзасы булган коммерциягә карамаган оешма турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 15. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 4 пунктчасы | Милеккә бушлай | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен яисә аның эшчәнлеген крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән муниципаль берәмлек территориясендә крестьян (фермер) хуҗалыгын алып бару өчен | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән һәм рөхсәт ителгән файдалану нигезендә биш елдан артык кулланыла торган җир кишәрлеге | *Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында ЕГРНнан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | алты елдан да ким булмаган вакытка түләүсез файдалануга бирелгән граждан | | |
| 16. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 5 пунктчасы | Милеккә бушлай | Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән белгечлек буенча муниципаль берәмлекләрдә төп эш урыны буенча эшләүче граждан | Шәхси торак төзү яки шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән, Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән муниципаль берәмлектә урнашкан җир кишәрлеге | Эшкә кабул итү турында приказ, хезмәт кенәгәсеннән өземтә яисә хезмәт шартнамәсе (контракт)<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә |
| 17. | Җир кодексының 39.5 маддәсенең 6 пунктчасы | Милеккә бушлай | Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар | Җир кишәрлекләрен бирү очраклары Россия Федерациясе субъекты | Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлекләрен бирү шартларын раслый торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадастр паспорты йә сорала торган |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | законы белән билгеләнә | җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе (мөрәҗәгать итүче гаризада җир кишәрлегенең кадастр номерын күрсәткән очракта)<br><br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә |
| 18. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 7 пунктчасы | Милеккә бушлай | Федераль законда билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләре һәм (яки) гражданнар тарафыннан булдырылган коммерцияле булмаган оешмалар | Җир кишәрлекләрен бирү очраклары федераль закон белән билгеләнә | Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җир кишәрлеген сатып алу хокукын раслый торган документлар<br><br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br><br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә |
| 19. | Җир кодексының | Милеккә | Гражданнарның | Җир | Җир кишәрлеген сатып алу хокукын |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 39.5 статьясындагы 7 пунктчасы | бушлай | Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә торган аерым категорияләре | кишәрлекләрен бирү очраклары Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә | раслый торган, Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән документлар |
| 20. | Җир кодексының 39.5 статьясындагы 8 пунктчасы | Милеккә бушлай | Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында җир кишәрлеге булган һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен билгеләнгән дини оешма | Җир кишәрлекләрен бирү очраклары Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә | Җир кишәрлеген сатып алу хокукын раслый торган, Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән документлар |

<1> Документлар чынлыкта (күчермәдә, әгәр документлар һәркем файдалана алырлык булса) йә башкарма хакимият органының яисә җирле үзидарә органының җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризаны кабул итүче вазыйфаи заты тарафыннан таныклана торган күчермәләрендә тапшырыла (җибәрелә).

<2> Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, N 44, 4147 ст., 2014, N 26, 3377 ст.

<3> "*"символ белән билгеләнгән документлар дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре (алга таба - вәкаләтле орган) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән эш итүгә вәкаләтле орган тарафыннан соратып алына.

4 нче кушымта

# Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы



5 нче кушымта

# Читтән торып эш урыннары исемлеге һәм документларны кабул итү графигы

| № т/б | Читтән торып эш урынының урнашу урыны | Хезмәт күрсәтә торган торак пунктлар | Документлар кабул итү графигы |
|---|---|---|---|
| 1. | Бело-Безводное ав., Юбилей ур., 13 нче йорт | Бело-Безводное ав., Местечко Раифа п., Садовый п. | Дүшәмбе, чәршәмбе, җомга: 08:00 – 15:00 Төшке аш вакыты: 12:00 – 13:00 |
| 2. | Осиново авылы, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 3 нче йорт | Осиново авылы, Яңа Тура авылы, Ремплер авылы, Воронино авылы, Новониколаевский п. | |
| 3. | Октябрь п., Беренче Май ур., 2 нче йорт | Октябрь п., Ореховка авылы | |
| 4. | Норлат ав., Гагарин ур., 46 нчы йорт | Норлаты авылы, Косякау авылы, Албаба авылы, Булатово авылы, Рязаново авылы, Татар Исламы авылы, Албаба п., Прибой п. | |
| 5. | Олы Җәке ав., Мәктәп ур., 1 нче йорт | Олы Җәке авылы, Уразлы авылы, Каратмән авылы, Никольский авылы, Үтәнгеш авылы | |
| 6. | Олы Карагуҗа авылы, Тынычлык ур., 41 нче йорт | Олы Карагуҗа авылы, Олы Күлбаш авылы, Кече Карагуҗа авылы, Синтәк авылы, Чирүчи авылы | |
| 7. | Большие Ключи авылы, Волостнов ур., 16а йорты | Большие Ключи авылы, Малые Ключи авылы, Ивановское авылы, Маевка авылы, Соловьевка авылы, Светлое Озеро п. | |
| 8. | Әйшә авылы, Яшьләр ур., 60 нчы йорт | Әйшә авылы, Ильинское авылы, Кызыл Яр авылы, Сафоново авылы, Успенка авылы, Нарат п. | |
| 9. | Мамадыш-Әкил ав., Ленин ур., 50 нче йорт | Мамадыш-Әкил авылы, Панау авылы, Рус Танае авылы, Татар Танае авылы | |
| 10. | Карамалы Тау штп, Беренче Май ур., 70 нче йорт | Карамалы Тау штп, Олы Ходяш авылы, Бритвино авылы, Ходяш п, Луговой п, | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Кече Ходяш п., Мизиново авылы, Исак авылы, Протопоповка авылы | |
| 11. | Васильево штп., Ирек ур., 1 нче йорт | Васильево штп | |

6 нчы кушымта

Татарстан Республикасы
______________муниципаль
районының мөлкәт һәм җир
мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә
______________________________

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

**Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында түбәндәгеләрне хәбәр итәм**
______________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтүнең атамасы)

Язылган:_________________________________________________________________
__________________________________________

Дөрес белешмәләр:__________________________________________________
_____________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны беркетәм:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны:

электрон документны_______ E-mail адресына җибәрү юлы белән

- расланган күчермә рәвешендә кәгазь чыганакта почта аша _________________________________________________________________ адресына җибәрүегезне сорыйм.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, тыю, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), муниципаль хезмәт күрсәтү максатыннан муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, шул исәптән автоматлаштырылган режимда эшкәртүгә үземнең ризалыгымны, шулай ук мин вәкиле булып торган затның ризалыгын раслыйм.

Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча _____________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

_______________ __________________ ( _________________)

(дата) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Кушымта
(белешмә
мәгълүмат)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Зеленодольск муниципаль районы Советы**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы | (84371)42513 | Sovet.ZMR@tatar.ru |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 8(84371)40576 | ispolkom.zmr@tatar.ru |

«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы » муниципаль учреждениесе

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Палата җитәкчесе | 8(84371)42107 | Palataizo@yandex.ru |
| Палата белгече | 8(84371) 57982/57827 | Palataizo@yandex.ru |

4 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2017 елның 23 маендагы 1313
номерлы

**Җир кишәрлеген бушлай сроклы файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) муниципаль милектәге җир кишәрлеген бушлай сроклы файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Регламентның гамәлдә булуы Зеленодольск муниципаль районы территориясендәге муниципаль милектәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә кагыла.

1.2. Хезмәт күрсәтүне алучылар (алга таба - мөрәҗәгать итүче): Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 маддәсенең 2 пунктында күрсәтелгән физик һәм юридик затлар (1-нче кушымта).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы - «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (алга таба - Палата).

Документларны кабул итү «Зеленодольск муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» муниципаль бюджет учреждениесендә (алга таба - КФҮ) башкарыла.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты.

Эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр билгеләнә.

Палатаның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 38 нче йорт

Эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

кабул итү көне: сишәмбе: 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр билгеләнә.

Палатаның белешмә телефоны: 4-21-07 (кабул итү бүлмәсе).

Керү шәхесне таныклый торган документлар буенча

Керү ирекле, алдан язылу таләп ителми.

КФҮ урнашкан урын: Зеленодольск шәһәре, Беренче Май ур., 14 нче йорт

Эш графигы:

дүшәмбе, чәршәмбе, шимбә, якшәмбе 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

сишәмбе, пәнҗешәмбе көнне 10.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр (2016 елның 07 сентябреннән сишәмбе көннәрендә 10:00 дән 20:00 гә кадәр);

җомга 7.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә (алга таба- «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындаЗеленодольск муниципаль районы сайтының (алга таба – Зеленодольск муниципаль районы сайты) адресы:http://zelenodolsk.tatarstan.ruПалатаның электрон адресы: Palataizo@yandex.ru к

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүматны түбәндәге ысуллар белән алырга мөмкин:

1) Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Палата биналарында урнашкан муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт күрсәтү турында белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша Зеленодольск муниципаль сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) ;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https:/ www.gosuslugi.ru);

5) Палатада:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон буенча;

язмача (шул исәптән ЭЦП таныклаган электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә - кәгазь саклагычта почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.4. Палата белгече мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматны Зеленодольск муниципаль районы сайтында һәм Палата биналарында мәгълүмат стендларында урнаштыруны тәэмин итә.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1994 елның 30 декабрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы белән (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.) (алга таба - РФ ГК);

Россия Федерациясенең 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы җир кодексы белән (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 29.10.2001, №44, 4147 ст.) (алга таба - РФ Җир кодексы);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 06.10.2003, №40, 3822 ст.);

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән(Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.) (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 27 ноябрендәге«Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын әзерләү таләпләрен раслау турында, территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын электрон документ рәвешендә әзерләгәндә территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы, әзерләү кәгазь чыганакта документ рәвешендә башкарыла торган территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы рәвешләрен раслау турында» 762 номерлы боерыгы белән Россия Федерациясе (алга таба-762 номерлы боерык)(Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru 18.02.2015);

Россия Икътисади үсеш министрлыгының "Мөрәҗәгать итүченең сату уздырмыйча җир кишәрлеге сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлеген раслау турында" 2015 елның 12 гыйнварындагы 1 нче боерыгы (алга таба 1 нче боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.02.2015);

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән(Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004) (алга таба - 45-ТРЗ номерлы ТР Законы);

«Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск

муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав) («Зеленодольская правда», №№253-256, 31.12.2005 ел);

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 1 февралендәге 39 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе турында нигезләмә (алга таба – Палата турында нигезләмә) («Зеленодольская правда», № 40, 01.03.2006);

«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесенең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән.

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, мөрәҗәгать итүчеләргә консультацияләр бирү тәрәзәсе;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән белешмәләрнең (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең) алар нигезендә белешмәләр кертелә торган документлардагы белешмәләргә тәңгәл килмәвенә китергән хата (басма язу хатасы, ялгыш, грамматик яки арифметик хата яки шуңа охшаш хата);

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза астында (алга таба - гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 п.). Гариза стандарт бланкта тутырыла (2 нче кушымта).

**2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты**

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандарт таләпләре эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күсәтүнең атамасы | Җир кишәрлеген бушлай сроклы файдалануга бирү | РФ ЗК.39.10 ст. |
| 2.2. Җирле үзидарәнең муниципаль хезмәтне турыдан-туры күрсәтүче башкарма-күрсәтмә органы исеме | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет),<br>«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (алга таба - Палата) | РФ Җир кодексының 3.2 статьясы,<br>ТР ЗК 5 статьясы,<br>Палата турында нигезләмә |
| Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Җир кишәрлегеннән бушлай сроклы файдалану шартнамәсе.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ ЗК. 39.1 ст.1 п. |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Җир кишәрлеген бушлай сроклы файдалануга бирү турында карар кабул итү гариза кергән көннән алып утыз көннән дә соңга калмыйча<br>Шартнамә теркәлгәннән соң бер көн эчендә имзаланган шартнамәне бирү | РФ ЗК 39.17 ст.5 п. |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле | 1) Гариза;<br>2) шәхесне таныклый торган документлар;<br>3) мөрәҗәгать итүче исеменнән мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ; | Россия Федерациясе Җир кодексы |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең төгәл исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | 4) мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очракта, чит ил дәүләт законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәве турындагы документларны рус теленә таныкланган тәрҗемәсе;<br>5) Гражданнар тарафыннан оештырылган коммерцияле булмаган оешма тарафыннан әзерләнгән җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү яки яшелчәчелек яки бакчачылык алып бару өчен әлеге оешмага түләүсез файдалануга җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән очракта, аның әгъзалары исемлеге.<br>6) Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алу хокукын раслаучы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән исемлектә каралган документлар, вәкаләтле органга ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә тапшырылырга тиешле документлардан тыш (мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә документлар исемлеге, хезмәт күрсәтү алучының категориясенә карап, 3 нче кушымтада китерелгән)<br>Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда | 1 нче боерык |

| | | |
|---|---|---|
| | түбәндәге ысулларның берсе тарафыннан бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>заказлы почта юлламасы белән тапшыру турында хәбәрнамә белән.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документларны үз карамагына алган дәүләт органы, | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар исемлеге, хезмәт күрсәтүләрне алучылар категориясенә карап, 3 нче кушымтада күрсәтелгән<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә хезмәт | 1 нче боерык |

| | | |
|---|---|---|
| җирле үзидарә органы яки оешма | күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә торган һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган гамәлгә ашыра торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | «Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» муниципаль бюджет учреждениесе;<br>Башкарма комитет җитәкчесе | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) документларның тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;<br>2) тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага теркәлгән документларда алдан әйтелмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлап була алмый торган җитди бозылулар булу;<br>4) Документлар тиешле булмаган органга тапшыру | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир кишәрлеге бирү турында гариза белән җир законнары нигезендә җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алу хокукына ия булмаган кеше мөрәҗәгать итүе<br>2)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада | Әлеге Регламент белән билгеләнә<br><br>Ст.39.16 ЗК РФ |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлеккә мирас итеп алынган милек яки аренда хокукында бирелгән булса, җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге хокукларга ия булучы мөрәҗәгать иткән яисә җир кишәрлеген РФ Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пункты нигезендә бирү турында гариза бирелгән очраклардан тыш;<br>3) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмага яшелчәчелек, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару яисә индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирелгән, моңа әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзасы яисә әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзасы гаризасы белән мөрәҗәгать итү очраклары керми, әгәр җир кишәрлеге гомуми файдаланудагы мөлкәткә керсә;<br>4) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарга яки юридик затларга караган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеш тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында яисә җир кишәрлегендә РФ Җир кодексының 39.36 статьясындагы 3 пунктында каралган объект урнаштырылган очраклардан тыш, һәм бу җир кишәрлегеннән файдалану рөхсәт | |

| | | |
|---|---|---|
| | ителгән файдалану нигезендә каршылык тудырмый яки бу биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса;<br>5)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеш тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында яисә җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән җир кишәрлегендә урнаштырылган очраклардан тыш, әлеге биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса;<br>6) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең әйләнештән алынган булуы яисә әйләнештә булуы чикләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокукта аны бирү рөхсәт ителмәү;<br>7) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган була, әгәр мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген милеккә бирү, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса яисә җир кишәрлеген арендага бирү , җир кишәрлеген | |

| | | |
|---|---|---|
| | резервлау турындагы карар гамәлдә булу срогыннан арткан вакытка түләүсез файдалану турында гариза белән мөрәҗәгать итсә, резервлау максатларында җир кишәрлеге бирү очрагыннан тыш;<br>8) җир кишәрлеге җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан,җир кишәрлеге бирү турында гариза белән шундый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, алардагы бүлмәләр, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы яки шундый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>9) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелешле территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән, мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>10)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне | |

| | | |
|---|---|---|
| | комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документациягә ярашлы рәвештә федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлегеннән төзелгән, җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки күрсәтелгән объектларны төзү буенча әлеге затның йөкләмәләрен күздә тоткан төзелеш территориясен үстерү турында шартнамә төзегән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>11) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турында хәбәр Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 19 пункты нигезендә урнаштырылган;<br>12) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктының 6 пунктчасында каралган аны сату яки аны арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру турында гариза керде, мондый җир кишәрлеге РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктындагы 4 пунктчасы һәм вәкаләтле орган нигезендә төзелгән очракта, мондый җир кишәрлеге РФ Җир кодексының 39.11 | |

| | | |
|---|---|---|
| | статьясының 8 пунктында каралган нигезләрдә әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән булса;<br>13)җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, дача хуҗалыгы яисә аның крестьян (фермер) хуҗалыгы өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәр басылып чыккан һәм урнаштырылган;<br>14)җир кишәрлеген рөхсәт ителгән куллану җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген куллану максатларына туры килми, территорияне планлаштыруның расланган проектына ярашлы рәвештә линия объектын урнаштыру очракларыннан тыш;<br>15) соратыла торган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча кулланылмый торган җир кишәрлекләре исемлегенә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кертелмәү, әгәр РФ ЗК 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән булса;<br>16) гражданнар тарафыннан төзелгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | коммерциягә карамаган оешманың җир кишәрлеген яшелчәчелек, бакчачылык алып бару өчен бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы федераль закон нигезендә билгеләнгән иң чик күләмнән артып китә;<br>17)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль планлаштыруның расланган документларына һәм (яки) территорияне планлаштыру буенча документациягә ярашлы рәвештә федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>18) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бинаны, корылманы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә урнаштыру өчен һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге бинаны, корылманы төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>19) хокукларның билгеләнгән рәвешендә җир кишәрлеге бирү рөхсәт ителми;<br>20) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән куллану төре билгеләнмәгән;<br>21) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән җир кишәрлеге билгеле бер җирләр категориясенә кертелмәгән;<br>22) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата, гамәлдә булу срогы тәмамланмаган килеш бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать иткән;<br>23)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган һәм гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү максаты мондый җир кишәрлеген тартып алган максатларга туры килми , мондый җир кишәрлегендә урнашкан күп фатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану сәбәпле, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир кишәрлекләреннән тыш;<br>24) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;<br>25) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасында, территорияне ызанлау проектында яки мондый җир кишәрлеге барлыкка килгән урман кишәрлекләренең урнашуы, чикләре, мәйданы һәм башка сан һәм сыйфат | |

| | | |
|---|---|---|
| | характеристикалары турындагы проект документациясендә күрсәтелгән мәйданнан ун процenttan артыграк. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Муниципаль хезмәттән файдалану турында гариза бирү вакыты, чират булган очракта, 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризасын теркәү, шул исәптән электрон формада теркәү срогы | Гариза килгәннән соң өч көн эчендә | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм | Кәгазьдә гариза Башкарма комитетка, КФҮкә, эш графигына туры китереп читтән торып эш урынына бирелә. | Әлеге Регламент белән билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| кабул итү урыннарына таләпләр, шул исәптән күрсәтелгән объектларның инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла:<br>һава кондиционерлау системасы;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документларны рәсмиләштерү өчен җиһазлар;<br>мәгълүмат стендлары белән;<br>инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү мөмкинлеген булдыра торган чаралар һәм җиһазлар белән. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең уңайлылык һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләре саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыннарында муниципаль хезмәт күрсәтү алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Палата бинасы җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашкан;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;<br>инвалидларга башка кешеләр белән беррәттән муниципаль хезмәт алуга комачаулаучы каршылыкларны җиңәргә ярдәм күрсәтү;<br>сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;<br>алып йөртүче этне Палата бинасына кертүгә рөхсәт;<br>Мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында | Әлеге Регламент белән билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр аша | муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән билгеләнә:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларга документларны тапшырганда чират булмавы ;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр булмау .<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазифаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла. Аралашу дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба - КФҮ) , КФҮ читтән торып эш урыннарында күрсәтелгәндә консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм тапшыруны КФҮ белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан https://www.gosuslugi.ru сайтында, Бердәм дәүләти | |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм муниципаль хезмәтләр порталында, КФУ сайтында алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү законда каралган очракта, гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) яисә Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (https:/ www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

**3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү срогы, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре**

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә эзлекле гамәлләр тасвирламасы

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр булдыру һәм җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге блок-схемасы 4 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр күрсәтү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче Палатага шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма гариза тапшыра һәм документларны шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә тапшыра. Документлар читтән торып эш урыны аша бирелергә мөмкин. Читтән торып эш урыннары исемлеге 5 нче кушымтада китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Интернет кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада кабул ителгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2.КФҮ белгече яки Башкарма комитет белгече, гаризалар кабул итүне алып баручы, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышанычнамә белән эш иткән очракта);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә (документларның күчермәләрен тиешенчә ясау, документларда төзәтүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка килештерелмәгән төзәтүләрнең булмавын).

Кисәтүләр булмаган очракта, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм аны махсус журналда терки;

мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне башкару датасы һәм вакыты турында билге куелган документлар исемлегенең күчермәсен тапшыра;

Гаризаны Палата җитәкчесенә карауга җибәрү.

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, КФҮ белгече йә Башкарма комитет белгече, документларны кабул итүне алып баручы, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар барлыгы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язма аңлатма белән документларны кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

гаризаны һәм документларны 15 минут эчендә кабул итү;

гаризаны теркәү, гариза килгәннән соң өч көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Палата җитәкчесе каравынаҗибәрелгән яисә мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Палата җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга юллау.

3.4.1. Палата белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә шушы Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турындагы рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә, соратып алына торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә

кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса, документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Палатага җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне әзерләү һәм аның нәтиҗәсен бирү

3.5.1. Палата белгече кергән документлар (белешмәләр) нигезендә шушы Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.consultantplus://offline/ref=4D18C437B63CEEDF120B82FCC49BB7D0A300352C2988FEA9F1A34DA3B1FD80C7AF93C36811830AA4EDCFCAE6V5K

3.5.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Палата белгече, баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли һәм Палата җитәкчесенә җибәрә.

Палата җитәкчесе хатны карый һәм имзалый, хат теркәү өчен Башкарма комитетның гомуми бүлегенә җибәрелә.

Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгече хатны терки һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган һәм теркәлгән хат.

3.5.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Палата белгече:

- бушлай сроклы файдалану шартнамәсе проектын әзерли (алга таба - Шартнамә проекты);

- Шартнамә проектын Палата җитәкчесе (ул вәкаләт биргән затка) белән килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы өч көн дәвамында гамәлгә ашырыла;

- Шартнамә проектын «ЗМР юридик бюросы» МБУ га килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы алты көн дәвамында гамәлгә ашырыла;

-Шартнамә проектын Башкарма комитет җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палата җитәкчесе һәм «ЗМР юридик бюросы» МБУ белән килештерелгән, Башкарма комитет җитәкчесенә (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) килештерүгә юнәлтелгән Шартнамә проекты .

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура соралган документлар (белешмәләр) керүнең тугыз көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Башкарма комитет җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат) Шартнамә проектын килештерә һәм имза салуга Палата җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Шартнамә проекты килештерүгә кергән өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.3. Палата җитәкчесе:

- Шартнамә проектын имзалый.

- аны Палата мөһере белән таныклый. Шартнамәнең имзаланган проекты Палата белгеченә җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: Шартнамәнең имзаланган проекты.

3.5.4. Палата белгече:

-Шартнамә проектын терки

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура Шартнамә проекты теркәлүгә кергән көннән алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, Шартнамәнең рәсмиләштерелгән проектын яисә баш тарту турында хатны бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту турында теркәлгән хат йә Шартнамә проекты кергән көннән бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.5.5. Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә)кул куйдырып Шартнамәнең рәсмиләштерелгән проектын яки баш тарту турында хат бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

- Шартнамә проекты яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хатны бирү - 15 минут эчендә, чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне;

- мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) хатны алу өчен Палатага махсус рәвештә килү мөмкин түгеллеге турында хәбәр иткән очракта,почта аша хат белән баш тарту турында хатны җибәрү -әлеге Регламентның 3.5.4 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә .

Процедуралар нәтиҗәсе: бирелгән Шартнамә проекты яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Шартнамә төзү һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Палата белгече:

шартнамә теркәү журналында Палата җитәкчесе кул куйган Шартнамәне терки;

мөрәҗәгать итүчегә кул куйдырып шартнамәне бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көнне, чират тәртибендә 15 минут дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән шартнамә һәм кабул итү-тапшыру акты.

3.7. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.7.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.7.2. Муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәк аша күрсәтү күпфункцияле үзәкнең билгеләнгән тәртиптә расланган хезмәт регламенты нигезендә башкарыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәт алуга КФҮдән документлар килгәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3 - 3.6 пунктлары нигезендә башкарыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документта техник хаталар ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Палатага түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (6 нчы кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган техник хаталы документны;

техник хаталар булуны дәлилли торган, юридик көчкә ия документларны.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырыла.

3.8.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итә, гариза белән кушымта итеп бирелгән документларны терки һәм аларны Палатага тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Палата белгеченә карауга юнәлтелгән гариза.

3.8.3. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатларында административ Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, һәм мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен кире алып, имза куйдырып, мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) төзәтмәләр кертелгән документны тапшыра яисә мөрәҗәгать итүче адресына, мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган документның төп нөсхәсен Палатага тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта кулланып) хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

**Муниципаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары**

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларга виза салу тора;

2) эш алып баруны билгеләнгән тәртиптә тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатендәге мәсьәләләр карап тикшерелергә мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр кылуга контроль һәм карарлар кабул итү максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы Палата җитәкчесе, шулай ук Палата белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазифаи затлар исемлеге җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрдәнләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланса, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре вакытында карап тикшерелмәве өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм кылынган гамәлләр (гамәл кылмау) өчен закон белән билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору муниципаль хезмәт күрсәткәндә Палата эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында

тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять итүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар Палатаның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре Палаткага, Башкарма комитетына яисә Муниципаль берәмлек советына судка кадәр тәртиптә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәттән файдалану турында мөрәҗәгатен теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Зеленодольск муниципаль районының башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять язма формада кәгазь чыганакта яки электрон формада бирелә.

Шикаятьне почта аша, КФҮ аша, "Интернет" челтәреннән файдаланып, http://uslugi.tatar.ru рәсми сайты, Зеленодольск муниципаль районы сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/), шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән алып унбиш көн эчендә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта - аны теркәгән көннән алып биш көн эчендә..

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтә торган органның, хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәренең исем-атамасы;

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр - физик зат яки исеме, мөрәҗәгать итүче - юридик зат урнашкан урын, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап бирелергә тиешле почта адресы турында белешмәләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда язылган хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа беркетелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять, аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы зат тарафыннан, имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Палата җитәкчесе (Башкарма комитет җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кабул ителгән карарныгамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән түләтү каралмаган акчаларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару формасында, шулай ук башка формаларда да шикаятьне канәгатьләндерә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап юллана.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазифаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

1 нче кушымта

Россия Федерациясе Җир кодексыннан өземтә

39.10 статья. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бушлай файдалануга бирү

2. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре түбәндәгеләргә бушлай файдалануга бирелергә мөмкин:

1) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән затларга бер елга кадәр;

2) Россия Федерациясе Җир кодексының 24 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән очракларда оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт җирләре рәвешендә хезмәткәр һәм оешма арасында төзелгән хезмәт шартнамәсе чорына;

3) дини оешмаларга дини яисә хәйрия билгеләнешендәге биналарны, корылмаларны ун елга кадәр урнаштыру өчен;

4) биналардан, корылмалардан түләүсез файдалану хокукында булган дини оешмаларга, мондый җир кишәрлекләрендә күрсәтелгән биналарга, корылмаларга хокуклар туктатылганчы, урнашкан булса;

5) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә күчемсез милек объектларын төзүгә яисә реконструкцияләүгә тулысынча федераль бюджет акчалары, Россия Федерациясе субъекты бюджеты чаралары яисә җирле бюджет чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган граждан-хокукый шартнамәләр төзелгән затларга әлеге шартнамәләрне үтәү чорына;

6) Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән муниципаль берәмлекләрдә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару яисә аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданга кимендә алты ел дәвамында;

7) индивидуаль торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен, Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән муниципаль берәмлекләрдә төп эш урыны буенча Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән белгечлекләр буенча эшләүче гражданнарга кимендә алты ел дәвамында;

8) гражданга бирелгән торак йорт рәвешендәге җир кишәрлегендә шул торак урыннан файдалану хокукы чорына хезмәт урыны урнашкан булса;

9) урман кишәрлекләрендә үз ихтыяҗлары өчен авыл хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру (шул исәптән умартачылык) максатларында кимендә биш елга;

10) әгәр мондый җир кишәрлекләре оборона ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча файдаланылмый торган җир кишәрлекләре исемлегенә кимендә биш елга кертелгән булса, биналар, корылмалар төзүне күздә тотмый торган, авыл хуҗалыгы, аучылык хуҗалыгы, урман хуҗалыгы һәм башка файдалану өчен гражданнарга һәм юридик затларга;

11) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмалар яшелчәчелек яисә бакчачылык алып бару өчен биш елдан да артык булмаган вакытка;

12) федераль законнарда каралган очракларда һәм срокта торак төзелеше максатларында гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмаларга;

13) Төньяк, Себер һәм Ерак Көнчыгышның аз санлы җирле халыкларына караган затларга һәм аларның общиналарына традицион яшәү урыннарында һәм традицион хуҗалык эшчәнлеге урыннарында, традицион яшәү рәвешен, Төньяк, Себер һәм Ерак Көнчыгышның аз санлы төп халыкларының традицион яшәү рәвешен, хуҗалык итү һәм кәсепләрен саклап калу һәм үстерү максатларында кирәкле биналар, корылмалар урнаштыру өчен, ун елдан да артык булмаган вакытка;

14) «Дәүләт оборона заказы турында» 2012 елның 29 декабрендәге 275-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон нигезендә ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә федераль бюджет акчалары исәбеннән дәүләт контрактлары төзелгән затларга, әгәр бу эшләрне башкару һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү өчен күрсәтелгән контрактны үтәү чорына җир кишәрлеге бирү кирәк булса;

15) Россия Федерациясе субъекты законы белән каралган һәм аерым категориядәге гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү өчен торак төзелеше максатларында , Россия Федерациясе субъекты тарафыннан федераль закон, Россия Федерациясе Президенты Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый акты, Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән, әлеге төзелешне гамәлгә ашыру чорына күрсәтелгән торак урыннарын төзү максатларында төзелгән коммерцияле булмаган оешмаларга;

16) дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлегенә түләүсез файдалану хокукы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеген тартып алу белән бәйле рәвештә, тартып алынган җир кишәрлеге урынына әлеге пунктта билгеләнгән вакытка, алынган җир кишәрлегенә түләүсез файдалану хокукы барлыкка килү нигезенә бәйле рәвештә, туктатылган затка.

2 нче кушымта

____________________________________________

(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)

____________________________________________

(физик затлар өчен-фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)

____________________________________________

(юридик затлар өчен-атамасы, урнашу урыны, оештыру-хокукый рәвеше, ЕГРЮЛ, ОГРН дәүләт теркәве турында белешмәләр)

____________________________________________

(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү турында
гариза

Сездән ________________________________________________нигезендә
(РФ Җир кодексының 39.10 ст.2 пунктында каралганнан нигез күрсәтелә).

________________________________________________________
(җир кишәрлегеннән файдалану максаты күрсәтелә)

адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге _____________ кв.м., кадастр номеры ______________________________________, рөхсәт ителгән файдалану төре белән, җирләр категориясеннән _____________________________ муниципаль район (шәһәр округы), торак пункт_________________ урамы. ________________ йорты, түләүсез сроклы файдалануга, торглар үткәрмичә.

Җир кишәрлеген файдалануның максаты ______________________________.

Өстәмә белешмәләр (түбәндәге шартлар булганда тутырыла):

__________________________________________________________________
җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеге урынына бирелгән очракта, дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеген алу турында карар реквизитлары;

____________________________________________________________________
әгәр җир кишәрлеге әлеге документта һәм (яисә) әлеге проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелгән булса, территориаль планлаштыру документын һәм (яисә) территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар реквизитлары;

____________________________________________________________________
сорала торган җир кишәрлеге төзелгән яисә аның чикләре әлеге карар нигезендә төгәлләштерелгән очракта, җир кишәрлеген алдан килештерү турында карар реквизитлары.

Гаризага түбәндәге документлар (сканерланган күчермәләр) теркәлә:

Физик затлар:

1) Шәхесне раслаучы документ күчермәсе (граждан өчен);

2) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкиле булса);

Юридик затлар:

1) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил гамәлдә булса);

*Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, тыю, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль*

*хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), муниципаль хезмәт күрсәтү максатыннан муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, шул исәптән автоматлаштырылган режимда эшкәртүгә үземнең ризалыгымны, шулай ук мин вәкиле булып торган затның ризалыгын раслыйм.*

*Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.*

*Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча ____________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.*

______________ __________________ ( _________________)
(дата) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

3 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлегеннән өземтә

| № т/б | Торглар үткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезләре | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алу хокукын раслый торган һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага теркәлә торган документлар<1> |
|---|---|---|---|---|---|
| 67. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Дәүләт хакимияте органы | Дәүләт хакимияте органнарының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге | Әлеге Исемлектә каралган, җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген бирүгә хокукын раслый торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 68. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Җирле үзидарә органы | Җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен башкару өчен кирәкле җир кишәрлеге | Әлеге Исемлектә каралган, җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген бирүгә хокукын раслый торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 69. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 1 | Түләүсез файдалануга | Дәүләт яки муниципаль (бюджет, казна, автоном) | Дәүләт яки муниципаль (бюджет, казна, автоном) | Әлеге Исемлектә каралган, җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген бирүгә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | пунктчасы | | учреждение | учреждение эшчәнлеген башкару өчен кирәкле җир кишәрлеге | хокукын раслый торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 70. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Казна предприятиесе | Казна предприятиесе эшчәнлеген башкару өчен кирәкле җир кишәрлеге | Әлеге Исемлектә каралган, җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген бирүгә хокукын раслый торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 71. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Россия Федерациясе президентларының үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан тарихи мирас үзәге | Үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Россия Федерациясе президентларының тарихи мирас үзәге эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге | Әлеге Исемлектә каралган, җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген бирүгә хокукын раслый торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 72. | Җир кодексының 39.10 статьясы 2 | Түләүсез файдалануга | Җир кишәрлеге даими (вакыты | Хезмәттәге җир кишәрлеге | Эшкә кабул итү турында приказ, хезмәт кенәгәсеннән өземтә яисә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | пунктының 2 пунктчасы | | чикләнмәгән) файдалану хокукында бирелгән оешма хезмәткәре | рәвешендә бирелә торган җир кишәрлеге | хезмәт шартнамәсе (контракт)<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә |
| 73. | Җир кодексының 39.10 статьясы 2 пунктының 3 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Дини оешма | Биналар урнаштыру, дини яисә хәйрия билгеләнешендәге корылмалар урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлеге | Әгәр бинага, корылмага хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса, мөрәҗәгать итүченең мондый бинага, корылмага хокукларын раслый (билгели) торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сорала торган җир кишәрлегендә урнашкан бинаның, корылманың кадрлар паспорты<br>*Сатып алына торган җир |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | кишәрлегенә һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына хокуклар турында ЕГРНнан өземтә йә соратыла торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәр итү<br><br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
3.2.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен Палатага шәхсән , телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма гариза тапшыра һәм документларны шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә тапшыра. Документлар читтән торып эш урыны аша бирелергә мөмкин. Читтән торып эш урыннары исемлеге 4 нче кушымтада китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Палатага электрон почта аша яисә Интернет аша җибәрелә. Электрон формада кабул ителгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2.КФҮ белгече яки гаризаларны кабул итүче Палата белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышанычнамә белән эш иткән очракта);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә (документларның күчермәләрен тиешенчә ясау, документларда төзәтүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка килештерелмәгән төзәтүләрнең булмавын).

Кисәтүләр булмаган очракта, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм аны махсус журналда терки;

мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне башкару датасы һәм вакыты турында билге куелган документлар исемлегенең күчермәсен тапшыра;

Гаризаны Палата җитәкчесенә карауга җибәрү.

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, КФҮ белгече йә Башкарма комитет белгече, документларны кабул итүне алып баручы, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар барлыгы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язма аңлатма белән документларны кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

гаризаны һәм документларны 15 минут эчендә кабул итү;

гариза кергән вакыттан аны бер көн эчендә теркәү.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Палата җитәкчесе каравынаҗибәрелгән яисә мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Палата җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара гарызнамәләрне муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Палата белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә шушы Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турындагы рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә, соратып алына торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса, документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Палатага җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне әзерләү һәм аның нәтиҗәсен бирү

3.5.1. Палата белгече кергән документлар (белешмәләр) нигезендә шушы Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

3.5.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Палата белгече, баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли һәм Палата җитәкчесенә җибәрә.

Палата җитәкчесе хатны карый һәм имзалый, хат теркәү өчен Башкарма комитетның гомуми бүлегенә җибәрелә.

Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгече хатны терки һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган һәм теркәлгән хат.

3.5.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Палата белгече:

- Җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе проектын әзерли (алга таба - Шартнамә проекты);

- Шартнамә проектын Палата җитәкчесе (ул вәкаләт биргән затка) белән килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы өч көн дәвамында гамәлгә ашырыла;

- Шартнамә проектын «ЗМР юридик бюросы» МБУ га килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы алты көн дәвамында гамәлгә ашырыла;

-Шартнамә проектын Башкарма комитет җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палата җитәкчесе һәм «ЗМР юридик бюросы» МБУ белән килештерелгән Шартнамә проекты Башкарма комитет җитәкчесен (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) килештерүгә юнәлтелгән.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура соралган документлар (белешмәләр) керүнең тугыз көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Башкарма комитет җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат)Шартнамә проектын килештерә һәм Палата җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура карар проекты һәм Шартнамә проекты килештерүгә кергәннән соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Шартнамәнең килештерелгән проекты.

3.5.3. Палата җитәкчесе Шартнамәгә кул куя һәм теркәү өчен Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура Шартнамә имза кую өчен килгәннән соң, бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: һәм Палата белгеченә юнәлдерелгән имзаланган Шартнамә.

3.5.4. Палата белгече:

Шартнамәләрне теркәү журналында Палата җитәкчесе кул куйган шартнамәне терки;

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура Шартнамә кабул ителгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән Шартнамә.

3.5.5. Палата белгече:

Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән Шартнамәне яисә баш тарту турында хатны бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар теркәлгән Шартнамә яисә баш тарту турында хат кергән көннән алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.5.6. Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә)кул куйдырып рәсмиләштерелгән Шартнамәне яки баш тарту турында хатны бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

- муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында Шартнамәне яисә хатны бирү - 15 минут эчендә, чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне;

- мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) хатны алу өчен Палатага махсус рәвештә килү мөмкин түгеллеге турында хәбәр иткән очракта,почта аша хат белән баш тарту турында хатны җибәрү -әлеге Регламентның 3.5.4 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә .

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән Шартнамә яисә баш тарту турында хат.

3.6. Шартнамә төзү һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Мөрәҗәгать итүче Шартнамәдә күрсәтелгән исәп-хисап счетына акча (Шартнамәдә күрсәтелгән сумма) күчерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар Шартнамәне теркәү мизгеленнән соң 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: санап үтелгән акчалар.

3.6.2. Палата белгече акча күчерү турында мәгълүмат алгач, өч нөсхәдә җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты төзи. Мөрәҗәгать итүчегә имза өчен җир кишәрлеген кабул итү - тапшыру актының 3 нөсхәсен бирә. Актны имзалаганнан соң, мөрәҗәгать итүчегә җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсенең 2 нөсхәсен, җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актының 2 нөсхәсен тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне, чират тәртибендә 15 минут дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән шартнамә һәм кабул итү-тапшыру акты.

3.7. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.7.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.7.2. Муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәк аша күрсәтү күпфункцияле үзәкнең билгеләнгән тәртиптә расланган хезмәт регламенты нигезендә башкарыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәт алуга КФҮдән документлар килгәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3 - 3.6 пунктлары нигезендә башкарыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документта техник хаталар ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Палатага түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (5 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган техник хаталы документны;

техник хаталар булуны дәлилли торган, юридик көчкә ия документларны.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырыла.

3.8.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итә, гариза белән кушымта итеп бирелгән документларны терки һәм аларны Палатага тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Палата белгеченә карауга юнәлтелгән гариза.

3.8.3. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатларында административ Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, һәм мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен кире алып, имза куйдырып, мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) төзәтмәләр кертелгән документны тапшыра яисә мөрәҗәгать итүче адресына, мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган документның төп нөсхәсен Палатага тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта кулланып) хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## Муниципаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларга виза салу тора;

2) эш алып баруны билгеләнгән тәртиптә тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатендәге мәсьәләләр карап тикшерелергә мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр кылуга контроль һәм карарлар кабул итү максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы Палата җитәкчесе, шулай ук Палата белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазифаи затлар исемлеге җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрдәнләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланса, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре вакытында карап тикшерелмәве өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм кылынган гамәлләр (гамәл кылмау) өчен закон белән билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору муниципаль хезмәт күрсәткәндә Палата эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять итүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар Палатаның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре Палаткага, Башкарма комитетына яисә Муниципаль берәмлек советына судка кадәр тәртиптә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәттән файдалану турында мөрәҗәгатен теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Зеленодольск муниципаль районының башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять язма формада кәгазь чыганакта яки электрон формада бирелә.

Шикаятьне почта аша, КФҮ аша, "Интернет" челтәреннән файдаланып, http://uslugi.tatar.ru рәсми сайты, Зеленодольск муниципаль районы сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/), шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән алып унбиш көн эчендә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта - аны теркәгән көннән алып биш көн эчендә..

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтә торган органның, хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәренең исем-атамасы;

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр - физик зат яки исеме, мөрәҗәгать итүче - юридик зат урнашкан урын, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап бирелергә тиешле почта адресы турында белешмәләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда язылган хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа беркетелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять, аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы зат тарафыннан, имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Палата җитәкчесе (Башкарма комитет җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кабул ителгән карарныгамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән түләтү каралмаган акчаларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару формасында, шулай ук башка формаларда да шикаятьне канәгатьләндерә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап юллана.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазифаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

1 нче кушымта

Россия Федерациясе Җир кодексыннан өземтә

39.3 статья. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен торгларда һәм торглар үткәрмичә сату очраклары

2. Торглар үткәрмичә түбәндәгеләрне сату башкарыла:

1) территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага бирелгән җир кишәрлегеннән (икътисадый класслы торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзегән юридик затка бирелгән җир кишәрлегеннән мондый торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага алынган җир кишәрлекләреннән тыш)төзелгән җир кишәрлекләренең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына ярашлы рәвештә, әлеге пунктның 2 һәм 4 пунктчаларында башкасы каралмаган очракта, территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү төзелгән затка;

2) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән җир кишәрлегеннән индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен (гомуми файдаланудагы мөлкәткә кертелгән җир кишәрлекләреннән тыш), әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзаларына яисә, әгәр бу коммерциягә карамаган оешма әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән каралган булса, әлеге җир кишәрлекләреннән;

3) гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы (гомуми файдаланудагы мөлкәткә кертелгән җир кишәрлекләреннән тыш) бакчачылыкны алып бару өчен төзелгән коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән җир кишәрлегеннән төзелгән җир кишәрлекләреннән;

4) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән җир кишәрлеген индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган әлеге коммерциягә карамаган оешмага бирү нәтиҗәсендә төзелгән җир кишәрлекләреннән;

5) юридик затка дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә төзелгән җир кишәрлекләре;

6) РФ ЗК 39.20 статьясында каралган очракларда биналар, корылмалар, мондый биналарның, корылмаларның яки аларда урнашкан биналарның хуҗалары урнашкан җир кишәрлекләре;

7) юридик затларга даими (сроксыз) файдалануда булган җир кишәрлекләре, күрсәтелгән юридик затларга, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән затлардан тыш;

8) «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда крестьян (фермер) хуҗалыгына яисә авыл хуҗалыгы оешмаларына җир кишәрлекләре;

9) авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен билгеләнгән һәм гражданга яки юридик затка, бу гражданга яки бу юридик затка әлеге граждан яки бу юридик зат белән аренда килешүе төзелгәннән соң өч ел узгач яки бу гражданга яки бу юридик затка мондый җир кишәрлеген тиешенчә куллану шарты белән җир кишәрлеген арендалау килешүе буенча хокуклар һәм бурычлар тапшырылганнан соң арендага бирелгән җир кишәрлекләре, әгәр бу граждан яки бу юридик зат мондый җир кишәрлеген торгсыз сатып алу-сату килешүе төзү турында гаризаны әлеге җир кишәрлеген арендалау килешүе тәмамланганчы биргән булса;

10) гражданнарга шәхси торак төзелеше, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, дача хуҗалыгы, гражданнарга яки крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен РФ ЗК 39.18 статьясына ярашлы рәвештә җир кишәрлекләре

2 нче кушымта

______________________________________________
(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)

_____________________________________________
(физик затлар өчен-фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)

____________________________________________
(юридик затлар өчен-атамасы, урнашу урыны, оештыру-хокукый рәвеше, ЕГРЮЛ, ОГРН дәүләт теркәве турында белешмәләр)

__________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату турында
гариза

Сездән _______________________________________________нигезендә
(РФ ЗК.39.3 ст.2 п.3, 39.5 ст., 39.6 ст.2 п.2 п., 39.10 ст.2 дә каралганнардан нигез күрсәтелә).
________________________________________________________өчен бирүне сорыйм.
(җир кишәрлегеннән файдалану максаты күрсәтелә)
адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге ___________ кв.м., кадастр номеры ____________________, рөхсәт ителгән файдалану төре белән, җирләр категориясеннән ______________________ муниципаль район (шәһәр округы), торак пункт_______________ урамы, милеккә, милеккә торглар үткәрмичә.
Өстәмә белешмәләр (түбәндәге шартлар булганда тутырыла):

________________________________________________________________________
җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеге урынына бирелгән очракта, дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеген алу турында карар реквизитлары;

________________________________________________________________________
әгәр җир кишәрлеге әлеге документта һәм (яисә) әлеге проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелгән булса, территориаль планлаштыру документын һәм (яисә) территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар реквизитлары;

________________________________________________________________________
сорала торган җир кишәрлеге төзелгән яисә аның чикләре әлеге карар нигезендә төгәлләштерелгән очракта, җир кишәрлеген алдан килештерү турында карар реквизитлары.

Гаризага түбәндәге документлар (сканерланган күчермәләр) теркәлә:

Физик затлар:

1) Шәхесне раслаучы документ күчермәсе (граждан өчен);

2) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкиле булса);

Юридик затлар:

1) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил гамәлдә булса);

*Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, тыю, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), муниципаль хезмәт күрсәтү максатыннан муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, шул исәптән автоматлаштырылган режимда эшкәртүгә үземнең ризалыгымны, шулай ук мин вәкиле булып торган затның ризалыгын раслыйм.*

*Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.*

*Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча _____________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.*

_______________ ___________________ ( _________________)

(дата) (имза) (ФИАт.и.)

3 нче кушымта

## Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы



4 нче кушымта

Читтән торып эш урыннары исемлеге һәм документларны кабул итү графигы

| № т/б | Читтән торып эш урынының урнашу урыны | Хезмәт күрсәтә торган торак пунктлар | Документларны кабул итү графигы. |
|---|---|---|---|
| 1. | Бело-Безводное ав., Юбилей ур., 13 нче йорт | Бело-Безводное ав., Местечко Раифа п., Садовый п. | Дүшәмбе, чәршәмбе, җомга: 08:00 – 15:00 Төшке аш вакыты: 12:00 – 13:00 |
| 2. | Осиново авылы, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 3 нче йорт | Осиново авылы, Яңа Тура авылы, Ремплер авылы, Воронино авылы, Новониколаевский п. | |
| 3. | Октябрь п., Беренче Май ур., 2 нче йорт | Октябрь п., Ореховка авылы | |
| 4. | Норлат ав., Гагарин ур., 46 нчы йорт | Норлаты авылы, Косякау авылы, Албаба авылы, Булатово авылы, Рязаново авылы, Татар Исламы авылы, Албаба п., Прибой п. | |
| 5. | Олы Җәке ав., Мәктәп ур., 1 нче йорт | Олы Җәке авылы, Уразлы авылы, Каратмән авылы, Никольский авылы, Үтәнгеш авылы | |
| 6. | Олы Карагуҗа авылы, Тынычлык ур., 41 нче йорт | Олы Карагуҗа авылы, Олы Күлбаш авылы, Кече Карагуҗа авылы, Синтәк авылы, Чирүчи авылы | |
| 7. | Большие Ключи авылы, Волостнов ур., 16а йорты | Большие Ключи авылы, Малые Ключи авылы, Ивановское авылы, Маевка авылы, Соловьевка авылы, Светлое Озеро п. | |
| 8. | Әйшә авылы, Яшьләр ур., 60 нчы йорт | Әйшә авылы, Ильинское авылы, Кызыл Яр авылы, Сафоново авылы, Успенка авылы, Нарат п. | |
| 9. | Мамадыш-Әкил ав., Ленин ур., 50 нче йорт | Мамадыш-Әкил авылы, Панау авылы, Рус Танае авылы, Татар Танае авылы | |
| 10. | Карамалы Тау штп, Беренче Май ур., 70 нче йорт | Карамалы Тау штп, Олы Ходяш авылы, Бритвино авылы, Ходяш п, Луговой п, | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Рече Ходяш п., Мизиново авылы, Исак авылы, Протопоповка авылы | |
| 11. | Васильево штп., Ирек ур., 1 нче йорт | Васильево штп | |

5 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль
районының мөлкәт һәм җир
мөнәсәбәтләре палатасы»
муниципаль учреждениесе
җитәкчесенә
______________________________

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

**Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында түбәндәгеләрне хәбәр итәм**
_______________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтүнең атамасы)

Язылган:_____________________________________________________________
___________________________________________

Дөрес белешмәләр:____________________________________________________
_____________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны беркетәм:

1.

2.

3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны:

электрон документны_______ E-mail адресына җибәрү юлы белән

- расланган күчермә рәвешендә кәгазь чыганакта почта аша ___________________________________________________________________ адресына җибәрүегезне сорыйм.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, тыю, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), муниципаль хезмәт күрсәтү максатыннан муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, шул исәптән автоматлаштырылган режимда эшкәртүгә үземнең ризалыгымны, шулай ук мин вәкиле булып торган затның ризалыгын раслыйм.

Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча _____________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

_______________ __________________ ( _________________)

(дата) (имза) (ФИАт.и.)

6 нчы кушымта

Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлегеннән өземтә

| № т/б | Торглар үткәрмичә генә җир кишәрлеге бирү нигезләре | Җир кишәрлеген түләүсез яисә түләүле бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Мөрәҗәгать итүче | Җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алу хокукын раслый торган һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага теркәлә торган документлар<1> |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасы <2> (алга таба - Җир кодексы) | Милеккә түләп | Территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән зат | Территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага бирелгән җир кишәрлегеннән төзелгән җир кишәрлеге | Территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә<br>*сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе <3><br>*Сатыла торган җир кишәрлегенә хокуклар турында Бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРН) белешмәләр алу (дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре барлыкка килү очракларыннан тыш) яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратыла торган белешмәләр булмау турында БДКМРда хәбәрнамә<br>*Расланган территорияне планлаштыру проекты һәм расланган территорияне |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | ызанлау проекты<br>*Юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРЮЛ) мөрәҗәгать итүче юридик зат турында өземтә |
| 2. | Җир кодексының 39.3 статьясының 2 пунктындагы 2 пунктчасыconsultantplus://offline/ref=B26B6A6E073857D0C774869730DC7E8581C67D0FE8E554E83B571511A596C4FCC3BC157798I7o2J | Милеккә түләп | Индивидуаль торак төзелеше максатларында комплексы үзләштерү өчен җир кишәрлеге бирелгән граждански тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма әгъзасы | Индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплексы үзләштерү өчен коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән җир кишәрлегеннән төзелгән индивидуаль торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең коммерциягә карамаган оешмада әгъзалыгын раслый торган документ<br>Сораштырыла торган җир кишәрлеген бүлү турында коммерциягә карамаган оешма органы карары<br>*Территорияне комплексы үзләштерү турында шартнамә<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРдан (дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре барлыкка килү очракларыннан тыш) яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләр булмау турында БДКМРдан өземтә<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Җир кодексының 39.3 статьясының 2 пунктындагы 3 пунктчасы | Милеккә түләп | Бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы өчен җир кишәрлеге бирелгән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма әгъзасы | Бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен билгеләнгән, коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы өчен бирелгән җир кишәрлегеннән төзелгән җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең соралган җир кишерләгенә хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар, әгәр мондый җир кишәрлегенә хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса<br><br>Мөрәҗәгать итүченең коммерциягә карамаган оешмада әгъзалыгын раслый торган документ<br><br>Коммерциягә карамаган оешма органының мөрәҗәгать итүчегә җир кишәрлеген бүлү турындагы карары<br><br>*Территорияне ызанлауның расланган проекты<br><br>*Коммерциягә карамаган берләшмә территориясен оештыру һәм төзү проекты (территорияне ызанлау расланган проекты булмаган очракта)<br><br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br><br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРдан (дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре барлыкка килү очракларыннан тыш) яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | хокуклар турында соратып алына торган белешмәләр булмау турында БДКМРдан өземтә<br><br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 4. | Җир кодексының 39.3 статьясының 2 пунктындагы 4 пунктчасы | Милеккә түләп | Индивидуаль торак төзелеше максатларында комплекслы үзләштерү өчен җир кишәрлеге бирелгән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма | Гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән җир кишәрлеген индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирү нәтиҗәсендә төзелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлеге | Гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген сатып алу турында коммерциягә карамаган оешма органы карары<br><br>*Территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә<br><br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br><br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРдан (дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре барлыкка килү очракларыннан тыш) яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләр булмау турында БДКМРдан өземтә<br><br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Җир кодексының 39.3 статьясының 2 пунктындагы 5 пунктчасы | Милеккә түләп | Дача хуҗалыгы алып бару өчен җир кишәрлеге бирелгән юридик зат | Юридик затка дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә төзелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлеге | Юридик зат органының гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген сатып алу турында карары<br><br>Мөрәҗәгать итүченең соралган җир кишерләгенә хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар, әгәр мондый җир кишәрлегенә хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса<br><br>*Территорияне ызанлауның расланган проекты<br><br>*Коммерциягә карамаган берләшмә территориясен оештыру һәм төзү проекты (территорияне ызанлау расланган проекты булмаган очракта)<br><br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br><br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРдан (дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре барлыкка килү очракларыннан тыш) яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләр булмау турында БДКМРдан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | *Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 6. | Җир кодексының 39.3 статьясы 2 пунктының 6 пунктчасы | Милеккә түләп | Бина, корылма яки бинадагы яки корылмадагы бүлмә хуҗасы | Бина, корылма урнашкан җир кишәрлеге | Әгәр бинага корылмага яки бүлмәгә хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса, мөрәҗәгать итүченең мондый бинага, корылмага яки бүлмәгә хокукын раслаучы (билгеләүче) документ<br><br>Әгәр мондый җир кишәрлегенә хокук БДКМРна теркәлмәгән булса, сорала торган җир кишәрлегенә мөрәҗәгать итүченең хокукларын таныклаучы (билгели торган) документ<br><br>Сорала торган җир кишәрлегендә урнашкан барлык биналар, корылмалар исемлеген үз эченә алган мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүчеләргә) аларның кадастр (шартлы, инвентарь) номерларын һәм адреслы ориентирларын күрсәтеп хәбәр итү<br><br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br><br>*Сорала торган җир кишәрлегендә урнашкан бинаның, корылманың кадрлар паспорты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | *Бина хуҗасы мөрәҗәгать иткән очракта, соралган җир кишәрлегендә урнашкан бинада, корылмадагы бинаның кадастр паспорты,<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына хокуклар турында ЕГРНнан өземтә йә соратыла торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәр итү<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә<br>*Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче булган индивидуаль  эшкуар турында өземтә |
| 7. | Җир кодексының 39.3 статьясы 2 пунктының 7 пунктчасы | Милеккә түләп | Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында файдаланучы юридик зат | Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында юридик зат милкендәге җир кишәрлеге | Мөрәҗәгать итүченең соралган җир кишерләгенә хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар, әгәр мондый җир кишәрлегенә хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 8. | Җир кодексының 39.3 статьясы 2 пунктының 8 пунктчасы | Милеккә түләп | Муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән файдаланучы һәм муниципаль милектәге җир өлешләре исәбенә бүлеп бирелгән крестьян (фермер) хуҗалыгы яисә авыл хуҗалыгы оешмасы | Муниципаль милектәге һәм муниципаль милектәге җир өлешләре исәбеннән бүлеп бирелгән җир кишәрлеге | *Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә<br>*Мөрәҗәгать итүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 9. | Җир кодексының 39.3 статьясы 2 пунктының 9 пунктчасы | Милеккә түләп | Авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлеген | Авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен билгеләнгән һәм аренда | "Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында" 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җир кишәрлегеннән файдалануны раслый |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | арендага алучы граждан яисә юридик зат | шартнамәсе нигезендә өч елдан артык файдаланыла торган җир кишәрлеге | торган документлар<br>*Сорала торган җир кишәрлегенең кадрлар паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында ЕГРНнан өземтә<br>*Мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә<br>*Мөрәҗәгать итүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 10. | Җир кодексының 39.3 статьясы 2 пунктының 10 пунктчасы | Милеккә түләп | Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү яки торак пункт , бакчачылык, дача хуҗалыгы чикләрендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән граждан | Торак пункт , бакчачылык, дача хуҗалыгы чикләрендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлеге | *Сорала торган җир кишәрлегенең кадастр паспорты йә сорала торган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе (мөрәҗәгать итүче гаризада җир кишәрлегенең кадастр номерын күрсәткән очракта)<br>*Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында БДКМРннан өземтә яисә күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә |

<1> Документлар чынлыкта (күчермәдә, әгәр документлар һәркем файдалана алырлык булса) йә башкарма хакимият органының яисә җирле үзидарә органының җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризаны кабул итүче вазыйфаи заты тарафыннан таныклана торган күчермәләрендә тапшырыла (җибәрелә).

<2> Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, N 44, 4147 ст., 2014, N 26, 3377 ст.

<3> "*"символ белән билгеләнгән документлар дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре (алга таба - вәкаләтле орган) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән эш итүгә вәкаләтле орган тарафыннан соратып алына.

Кушымта
(белешмә
мәгълүмат)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Зеленодольск муниципаль районы Советы**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы | (84371)42513 | Sovet.ZMR@tatar.ru |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 8(84371)40576 | ispolkom.zmr@tatar.ru |

«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы » муниципаль учреждениесе

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Палата җитәкчесе | 8(84371)42107 | Palataizo@yandex.ru |
| Палата белгече | 8(84371) 57982/57827 | Palataizo@yandex.ru |

6 нчы кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 23 маендагы
1313 номерлы карарына

# Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү, хезмәт күрсәтү)стандартын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Регламентның гамәлдә булуы Зеленодольск муниципаль районы территориясендәге муниципаль милектәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә кагыла.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алучылар: Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 ст. 2 пунктында санап үтелгән физик һәм юридик затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүче) (1 нче кушымта).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы - «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (алга таба - Палата).

Документларны кабул итү «Зеленодольск муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» муниципаль бюджет учреждениесендә (алга таба - КФҮ) башкарыла.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты.

Эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр билгеләнә.

Палатаның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 38 нче йорт

Эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

кабул итү көне: сишәмбе: 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр билгеләнә.

Палатаның белешмә телефоны: 4-21-07 (кабул итү бүлмәсе).

Керү шәхесне таныклый торган документлар буенча

Керү ирекле, алдан язылу таләп ителми.

КФҮ урнашкан урын: Зеленодольск шәһәре, Беренче Май ур., 14 нче йорт

Эш графигы:

дүшәмбе, чәршәмбе, шимбә, якшәмбе 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

сишәмбе, пәнҗешәмбе көнне 10.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр (2016 елның 07 сентябреннән сишәмбе көннәрендә 10:00 дән 20:00 гә кадәр);

җомга 7.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә (алга таба- «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындаЗеленодольск муниципаль районы сайтының (алга таба – Зеленодольск муниципаль районы сайты) адресы:http://zelenodolsk.tatarstan.ru Палатаның электрон адресы: Palataizo@yandex.ru к

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүматны түбәндәге ысуллар белән алырга мөмкин:

1) Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Палата биналарында урнашкан муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт күрсәтү турында белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша Зеленодольск муниципаль сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) ;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https:/ www.gosuslugi.ru);

5) Палатада:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон буенча;

язмача (шул исәптән ЭЦП таныклаган электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә - кәгазь саклагычта почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.4. Палата белгече мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматны Зеленодольск муниципаль районы сайтында һәм Палата биналарында мәгълүмат стендларында урнаштыруны тәэмин итә.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Граждан кодексының 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301ст. );

Россия Федерациясенең 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы җир кодексы (алга таба - РФ Җир кодексы) (РФ законнар җыентыгы, 29.10.2001, №44, 4147 ст. );

“Җир төзелеше турында” 2001 елның 18 июнендәге 78-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 78-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 25.06.2001, №26, 2582 ст.);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 06.10.2003, №40, 3822 ст.);

“Конкуренцияне яклау турында” 26.07.2006г. № 135-ФЗ Федераль законы (алга таба - 135-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы), 31.07.2006, N 31 (1 к.), 3434 ст.);

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 16 июлендәге «Дәүләт яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен арендалаганда аренда түләвен билгеләүнең төп принциплары турында һәм аренда түләвен билгеләү кагыйдәләрен, шулай ук Россия Федерациясе милкендәге җир өчен аренда түләвен кертү тәртибен, шартларын һәм срокларын билгеләү кагыйдәләре турында» 582 номерлы карары (алга таба - 582 номерлы карар) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.07.2009, №30, 3821 ст.);

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 27 ноябрендәге«Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын әзерләү таләпләрен раслау турында, территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын электрон документ рәвешендә әзерләгәндә территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы, әзерләү кәгазь чыганакта документ рәвешендә башкарыла торган территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы рәвешләрен раслау турында» 762 номерлы боерыгы белән Россия Федерациясе (алга таба-762 номерлы боерык)(Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru 18.02.2015);

Россия Икътисади үсеш министрлыгының "Мөрәҗәгать итүченең сату уздырмыйча җир кишәрлеге сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлеген раслау турында" 2015 елның 12 гыйнварындагы 1 нче боерыгы (алга таба 1 нче боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.02.2015);

Татарстан Республикасы Җир кодексы белән 1998елның 10 июлендәге 1736 номерлы (алга таба - ТР Җир кодексы) (Татарстан Республикасы, № 10-11, 22.01.2005);

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Республикасы, № 155-156, 03.08.2004);

«Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав) («Зеленодольская правда», №№253-256, 31.12.2005 ел);

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 1 февралендәге 39 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе турында нигезләмә (алга таба – Палата турында нигезләмә) («Зеленодольская правда», № 40, 01.03.2006);

«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесенең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән.

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, мөрәҗәгать итүчеләргә консультацияләр бирү тәрәзәсе;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән белешмәләрнең (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең) алар нигезендә белешмәләр кертелә торган документлардагы белешмәләргә тәңгәл килмәвенә китергән хата (басма язу хатасы, ялгыш, грамматик яки арифметик хата яки шуңа охшаш хата);

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза астында (алга таба - гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 п.). Гариза стандарт бланкта тутырыла (2 нче кушымта).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандарт таләпләре эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күсәтүнең атамасы | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү | РФ ЗК 39.6 ст. |
| 2.2. Җирле үзидарәнең муниципаль хезмәтне турыдан-туры күрсәтүче башкарма-күрсәтмә органы исеме | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет),<br>«Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (алга таба - Палата) | РФ Җир кодексының 3.2 статьясы,<br>ТР ЗК 5 статьясы,<br>Палата турында нигезләмә |
| Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | 1.Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе, җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты<br>2.Хезмәтне күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ Җир кодексының 3.2 статьясы,<br>ТР ЗК 5 статьясы,<br>Палата турында нигезләмә |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Гариза кергән көннән соң утыз көннән дә соңга калмыйча, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү йә хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат юлламасы. | РФ ЗК 39.17 ст.5 п. |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле | 1) Гариза;<br>2) шәхесне таныклый торган документлар;<br>3) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган | ЗК РФ.39.17 ст ; 39.15 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең төгәл исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил булса);<br>4) мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очракта, чит ил дәүләт законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәве турындагы документларны рус теленә таныкланган тәрҗемәсе;<br>5) Гражданнар тарафыннан оештырылган коммерцияле булмаган оешма тарафыннан әзерләнгән җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү яки яшелчәчелек яки бакчачылык алып бару өчен әлеге оешмага түләүсез файдалануга җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән очракта, аның әгъзалары исемлеге.<br>6) Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алу хокукын раслаучы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән исемлектә каралган документлар, вәкаләтле органга ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә тапшырылырга тиешле документлардан тыш (мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә документлар исемлеге, хезмәт күрсәтү алучының категориясенә карап, 3 нче кушымтада китерелгән)<br>Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган. | 1 нче боерык |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза һәм аңа теркәлгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда түбәндәге ысулларның берсе тарафыннан бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>заказлы почта юлламасы белән тапшыру турында хәбәрнамә белән.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар исемлеге, хезмәт күрсәтүләрне алучылар категориясенә карап, 3 нче кушымтада күрсәтелгән<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән | 1 нче боерык |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе; әлеге документларны үз карамагына алган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә торган һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган гамәлгә ашыра торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | «Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» муниципаль бюджет учреждениесе;<br>Башкарма комитет җитәкчесе | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) документларның тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;<br>2) тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага теркәлгән документларда алдан әйтелмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлап була алмый торган җитди бозылулар булу;<br>4) Документлар тиешле булмаган органга тапшыру | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Туктап тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир кишәрлеге бирү турында гариза белән җир законнары нигезендә җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сатып алу хокукына ия булмаган кеше мөрәҗәгать итүе | РФ ЗК 39.16 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | 2)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлеккә мирас итеп алынган милек яки аренда хокукында бирелгән булса, җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге хокукларга ия булучы мөрәҗәгать иткән яисә җир кишәрлеген РФ Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пункты нигезендә бирү турында гариза бирелгән очраклардан тыш;<br>3) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмага яшелчәчелек, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару яисә индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирелгән, моңа әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзасы яисә әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзасы гаризасы белән мөрәҗәгать итү очраклары керми, әгәр җир кишәрлеге гомуми файдаланудагы мөлкәткә керсә;<br>4) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарга яки юридик затларга караган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеш тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында яисә җир кишәрлегендә РФ Җир кодексының 39.36 статьясындагы 3 пунктында каралган объект урнаштырылган очраклардан тыш, | |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм бу җир кишәрлегеннән файдалану рөхсәт ителгән файдалану нигезендә каршылык тудырмый яки бу биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса;<br>5)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеш тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында яисә җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән җир кишәрлегендә урнаштырылган очраклардан тыш, әлеге биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса;<br>6) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең әйләнештән алынган булуы яисә әйләнештә булуы чикләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокукта аны бирү рөхсәт ителмәү;<br>7) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган була, әгәр мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген милеккә бирү, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану турында гариза белән мөрәҗәгать иткән булса яисә | |

| | | |
|---|---|---|
| | җир кишәрлеген арендага бирү , җир кишәрлеген резервлау турындагы карар гамәлдә булу срогыннан арткан вакытка түләүсез файдалану турында гариза белән мөрәҗәгать итсә, резервлау максатларында җир кишәрлеге бирү очрагыннан тыш;<br>8) җир кишәрлеге җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан,җир кишәрлеге бирү турында гариза белән шундый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, алардагы бүлмәләр, төзелеп бетмәгән объектның хуҗасы яки шундый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>9) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелешле территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән, мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>10)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документациягә ярашлы рәвештә федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлегеннән төзелгән, җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки күрсәтелгән объектларны төзү буенча әлеге затның йөкләмәләрен күздә тоткан төзелеш территориясен үстерү турында шартнамә төзегән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>11) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турында хәбәр Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 19 пункты нигезендә урнаштырылган;<br>12) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктының 6 пунктчасында каралган аны сату яки аны арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру турында гариза керде, мондый җир кишәрлеге РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктындагы 4 пунктчасы һәм вәкаләтле орган нигезендә төзелгән очракта, | |

| | | |
|---|---|---|
| | мондый җир кишәрлеге РФ Җир кодексының 39.11 статьясының 8 пунктында каралган нигезләрдә әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән булса;<br>13)җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, дача хуҗалыгы яисә аның крестьян (фермер) хуҗалыгы өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәр басылып чыккан һәм урнаштырылган;<br>14)җир кишәрлеген рөхсәт ителгән куллану җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген куллану максатларына туры килми, территорияне планлаштыруның расланган проектына ярашлы рәвештә линия объектын урнаштыру очракларыннан тыш;<br>15) соратыла торган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча кулланылмый торган җир кишәрлекләре исемлегенә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кертелмәү, әгәр РФ ЗК 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән булса; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 16) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешманың җир кишәрлеген яшелчәчелек, бакчачылык алып бару өчен бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы федераль закон нигезендә билгеләнгән иң чик күләмнән артып китә;<br>17)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль планлаштыруның расланган документларына һәм (яки) территорияне планлаштыру буенча документациягә ярашлы рәвештә федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>18) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бинаны, корылманы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә урнаштыру өчен һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге бинаны, корылманы төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>19) хокукларның билгеләнгән рәвешендә җир кишәрлеге бирү рөхсәт ителми;<br>20) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән куллану төре билгеләнмәгән; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 21) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге билгеле бер җирләр категориясенә кертелмәгән;<br>22) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата, гамәлдә булу срогы тәмамланмаган килеш бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать иткән;<br>23)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган һәм гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү максаты мондый җир кишәрлеген тартып алган максатларга туры килми , мондый җир кишәрлегендә урнашкан күп фатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану сәбәпле, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир кишәрлекләреннән тыш;<br>24) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;<br>25) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасында, мондый җир кишәрлеге барлыкка килгән территорияне ызанлау проектында яки урман кишәрлекләренең урнашуы, | |

| | | |
|---|---|---|
| | чикләре, мәйданы һәм башка сан һәм сыйфат характеристикалары турындагы проект документациясендә күрсәтелгән мәйданнан ун проценттан артыграк | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Муниципаль хезмәттән файдалану турында гариза бирү вакыты, чират булган очракта, 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсен теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза килгәннән соң өч көн эчендә | Әлеге Регламент белән билгеләнә |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм | Кәгазьдә гариза Башкарма комитетка, КФҮкә, эш графигына туры китереп читтән торып эш урынына бирелә. | Әлеге Регламент белән билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| кабул итү урыннарына таләпләр, шул исәптән күрсәтелгән объектларның инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла:<br>һава кондиционерлау системасы;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документларны рәсмиләштерү өчен җиһазлар;<br>мәгълүмат стендлары белән;<br>инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү мөмкинлеген булдыра торган чаралар һәм җиһазлар белән. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең уңайлылык һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләре саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыннарында муниципаль хезмәт күрсәтү алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Палата бинасы җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашкан;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;<br>инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәт алуга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;<br>алып йөртүче этне Палата бинасына кертүгә рөхсәт;<br>Мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында | Әлеге Регламент белән билгеләнә |

| | | |
|---|---|---|
| исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр аша | муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән билгеләнә:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларга документларны тапшырганда чират булмавы ;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр булмау .<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазифаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла. Аралашу дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба - КФҮ) , КФҮ читтән торып эш урыннарында күрсәтелгәндә консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм тапшыруны КФҮ белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан https://www.gosuslugi.ru сайтында, Бердәм дәүләти | |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм муниципаль хезмәтләр порталында, КФҮ сайтында алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү законда каралган очракта, гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) яисә Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (https:/ www.gosuslugi.ru/аша тапшырыла. | Әлеге Регламент белән билгеләнә |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү срогы, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә эзлекле гамәлләр тасвирламасы

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр булдыру һәм җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге блок-схемасы 4 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр күрсәтү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче Палатага шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма гариза тапшыра һәм документларны шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә тапшыра. Документлар читтән торып эш урыны аша бирелергә мөмкин. Читтән торып эш урыннары исемлеге 5 нче кушымтада китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Интернет кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада кабул ителгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2.КФҮ белгече яки Башкарма комитет белгече, гаризалар кабул итүне алып баручы, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышанычнамә белән эш иткән очракта);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә (документларның күчермәләрен тиешенчә ясау, документларда төзәтүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка килештерелмәгән төзәтүләрнең булмавын).

Кисәтүләр булмаган очракта, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм аны махсус журналда терки;

мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне башкару датасы һәм вакыты турында билге куелган документлар исемлегенең күчермәсен тапшыра;

Гаризаны Палата җитәкчесенә карауга җибәрү.

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, КФҮ белгече йә Башкарма комитет белгече, документларны кабул итүне алып баручы, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар барлыгы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язма аңлатма белән документларны кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

гаризаны һәм документларны 15 минут эчендә кабул итү;

гаризаны теркәү, гариза килгәннән соң өч көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Палата җитәкчесе каравынаҗибәрелгән яисә мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Палата җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга юллау.

3.4.1. Палата белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә шушы Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турындагы рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә, соратып

алына торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса, документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Палатага җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне әзерләү һәм аның нәтиҗәсен бирү

3.5.1. Палата белгече кергән документлар (белешмәләр) нигезендә шушы Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

3.5.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Палата белгече, баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли һәм Палата җитәкчесенә җибәрә.

Палата җитәкчесе хатны карый һәм имзалый, хат теркәү өчен Башкарма комитетның гомуми бүлегенә җибәрелә.

Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгече хатны терки һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: баш тарту турында карар кабул итүнең барлык нигезләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган һәм теркәлгән хат.

3.5.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Палата белгече:

- җир кишәрлеген арендалау Шартнамәсе проектын әзерли (алга таба - Шартнамә проекты);

- Шартнамә проектын Палата җитәкчесе (ул вәкаләт биргән затка) белән килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы өч көн дәвамында гамәлгә ашырыла;

- Шартнамә проектын «ЗМР юридик бюросы» МБУ га килештерүгә җибәрә. Килештерү процедурасы алты көн дәвамында гамәлгә ашырыла;

-Шартнамә проектын Башкарма комитет җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палата җитәкчесе һәм «ЗМР юридик бюросы» МБУ тарафыннан килештерелгән Шартнамә проекты Башкарма комитет җитәкчесен (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) килештерүгә юнәлтелгән.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура соралган документлар (белешмәләр) алынганнан соң тугыз көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Башкарма комитет җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат) килештерә Шартнамә проекты.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Шартнамә проекты килештерүгә өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Шартнамәнең килештерелгән проекты.

3.5.3. Палата җитәкчесе Шартнамәгә кул куя һәм теркәү өчен Палата белгеченә җибәрә.

3.5.4. Палата белгече:

Шартнамәләрне теркәү журналында Палата җитәкче кул куйган шартнамәне терки;

3.5.5. Палата белгече:

Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән Шартнамәне яисә баш тарту турында хатны бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар теркәлгән Шартнамә яисә баш тарту турында хат кергән көннән алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.5.6. Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә)кул куйдырып рәсмиләштерелгән Шартнамәне яки баш тарту турында хатны бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

- муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында Шартнамәне яисә хатны бирү - 15 минут эчендә, чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне;

- мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) хатны алу өчен Палатага махсус рәвештә килү мөмкин түгеллеге турында хәбәр иткән очракта,почта аша хат белән баш тарту турында хатны җибәрү -әлеге Регламентның 3.5.4 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә .

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән Шартнамә яисә баш тарту турында хат.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Палата белгече:

Шартнамәләрне теркәү журналында Палата җитәкчесе кул куйган Шартнамәне терки;

мөрәҗәгать итүчегә кул куйдырып шартнамәне бирә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән Шартнамә .

3.7. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.7.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.7.2. Муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәк аша күрсәтү күпфункцияле үзәкнең билгеләнгән тәртиптә расланган хезмәт регламенты нигезендә башкарыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәт алуга КФҮдән документлар килгәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3 - 3.6 пунктлары нигезендә башкарыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документта техник хаталар ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Палатага түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (6 нчы кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган техник хаталы документны;

техник хаталар булуны дәлилли торган, юридик көчкә ия документларны.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырыла.

3.8.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итә, гариза белән кушымта итеп бирелгән документларны терки һәм аларны Палатага тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Палата белгеченә карауга юнәлтелгән гариза.

3.8.3. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатларында административ Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, һәм мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен кире алып, имза куйдырып, мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) төзәтмәләр кертелгән документны тапшыра яисә мөрәҗәгать итүче адресына, мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган документның төп нөсхәсен Палатага тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта кулланып) хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## Муниципаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларга виза салу тора;

2) эш алып баруны билгеләнгән тәртиптә тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатендәге мәсьәләләр карап тикшерелергә мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр кылуга контроль  һәм карарлар кабул итү максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы Палата җитәкчесе, шулай ук Палата белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазифаи затлар исемлеге җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрдәнләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланса, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре вакытында карап тикшерелмәве өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм кылынган гамәлләр (гамәл кылмау) өчен закон белән билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору муниципаль хезмәт күрсәткәндә Палата эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында

тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять итүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар Палатаның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре Палаткага, Башкарма комитетына яисә Муниципаль берәмлек советына судка кадәр тәртиптә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәттән файдалану турында мөрәҗәгатен теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Зеленодольск муниципаль районының башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять язма формада кәгазь чыганакта яки электрон формада бирелә.

Шикаятьне почта аша, КФҮ аша, "Интернет" челтәреннән файдаланып, http://uslugi.tatar.ru рәсми сайты, Зеленодольск муниципаль районы сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/), шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән алып унбиш көн эчендә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә яисә

мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта - аны теркәгән көннән алып биш көн эчендә..

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтә торган органның, хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәренең исем-атамасы;

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр - физик зат яки исеме, мөрәҗәгать итүче - юридик зат урнашкан урын, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап бирелергә тиешле почта адресы турында белешмәләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда язылган хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа беркетелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять, аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы зат тарафыннан, имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Палата җитәкчесе (Башкарма комитет җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кабул ителгән карарныгамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән түләтү каралмаган акчаларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару формасында, шулай ук башка формаларда да шикаятьне канәгатьләндерә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап юллана.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазифаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

1 нче кушымта

Россия Федерациясе Җир кодексыннан өземтә

39.6 статья. Дәүләт яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен торгларда арендага бирү һәм торглар үткәрмичә бирү очраклары

2. Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген аренда килешүе, бирелгән очракта, торглар үткәрмичә төзелә:

1) юридик затларга Россия Федерациясе Президенты Указы яисә күрсәтмәсе нигезендә җир кишәрлеге;

2) юридик затларга, күрсәтелгән объектларның, инвестиция проектларының Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән критерийларга туры килү шарты белән, социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсе нигезендә җир кишәрлеге;

3) юридик затларга, күрсәтелгән объектларның, инвестиция проектларының Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән критерийларга туры килү шарты белән, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты күрсәтмәсе нигезендә;

4) Россия Федерациясенең халыкара йөкләмәләрен үтәү өчен җир кишәрлеге, шулай ук электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су бүлеп бирү, элемтә, нефть үткәргечләр, федераль, региональ яисә җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру өчен билгеләнгән объектларны урнаштыру өчен юридик затларга;

5) дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән төзелгән, шул исәптән территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирелгән җир кишәрлегеннән, әгәр әлеге пунктның 6 һәм 8 пунктчаларында башкасы каралмаган булса, мондый җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзелгән затка;

6) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән җир кишәрлегеннән индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен төзелгән җир кишәрлегеннән, гомуми файдаланудагы мөлкәткә кертелгән җир кишәрлекләреннән тыш, әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән каралган яисә, әгәр бу әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән каралган булса;

7) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма тарафыннан төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән җир кишәрлеге, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару өчен, гомуми файдаланудагы мөлкәткә кертелгән җир кишәрлекләреннән тыш, әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзаларына;

8) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешма тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып бару өчен яисә индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирелгән җир кишәрлеге әйләнешендә чикләнгән бүленү нәтиҗәсендә төзелгән җир кишәрлеге, әлеге коммерциягә карамаган оешма;

9) әлеге күчемсез мөлкәт объектлары хуҗалык карамагындагы хокукта яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясында каралган очракларда

оператив идарә итү хокукында бирелгән биналар, корылмалар, биналар, корылмалар милекчеләренә һәм (яисә) затларга урнашкан җир кишәрлеге;

10) төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлеге, әлеге статьяның 5 пунктында каралган очракларда төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары хуҗаларына төзелешне тәмамлау өчен бер тапкыр;

11) юридик затлардан даими (вакыты чикләнмәгән) файдаланудагы җир кишәрлеген, әлеге җирдән файдаланучыларга, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән юридик затлардан тыш;

12) «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда крестьян (фермер) хуҗалыгына яисә авыл хуҗалыгы оешмасына җир кишәрлеге;

13) төзелгән территория чикләрендә төзелгән җир кишәрлеге, төзелгән территорияне үстерү турында килешү төзелгән зат;

13.1) эконом класслы торак төзү максатларында территорияне үзләштерү өчен яисә эконом класслы торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен территорияне үзләштерү турында шартнамә яисә икътисадый класслы торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзегән юридик затка;

14) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә җир кишәрлекләрен беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алуга хокукы булган гражданнарга җир кишәрлеген;

15) индивидуаль торак төзелеше, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга җир кишәрлеге, бакчачылык, дача хуҗалыгы чикләрендә, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, аның эшчәнлеген Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә гамәлгә ашыру өчен;

16) гражданга яисә юридик затка аренда хокукында бирелгән җир кишәрлеге урынына дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеге урынына;

17) Россия Федерациясендә казак җәмгыятьләренең дәүләт реестрына кертелгән дини оешмаларга, казак җәмгыятьләренә (алга таба - казак җәмгыятьләре) җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы җитештерүен гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән территориядә казак җәмгыятьләренең традицион тормыш рәвешен һәм хуҗалык итүен саклау һәм үстерү өчен;

18) Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә, шул исәптән мондый җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган йә әйләнештә чикләнгән булса, җир кишәрлеген милеккә сатып алу хокукына ия булган затка;

19) җир кишәрлеге гражданга - печәнлекләр, авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү, яшелчәчелек алып бару яисә торак пункт чикләрендә урнашкан җир кишәрлеге алып бару өчен, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданга;

20) җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр башкару өчен кирәкле җир кишәрлеген файдаланучыга;

21) махсус икътисадый зона чикләрендә яисә аның янәшәсендәге территориядә урнашкан җир кишәрлеге, махсус икътисадый зона резиденты яисә идарәче компания аны махсус икътисадый зоналар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә федераль бюджет, Россия Федерациясе субъекты бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән, махсус икътисадый зона чикләрендә һәм аның янәшәсендәге территориядә күчемсез мөлкәт объектларын финанслауның бюджеттан тыш чыганакларын булдыру һәм әлеге һәм әлек төзелгән күчемсез мөлкәт объектлары белән идарә итү өчен җәлеп ителгән очракта;

